«Гөлназ» 49 нчы балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле
гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

Килешенде:
Өлкән тәрбияче
_______ Хөснетдинова Д.Р.
«_31_» ___08___ 2022 ел

Раслыйм
«Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы»
МБМББ җитәкчесе :
_______ Габидуллина Э.С.
«_31_» ___08___ 2022 ел

# 8 нче кечкенә нәниләр (1-2 яшь) төркеменең 2022-2023 нче уку елына эш программасы

Төзүчеләр:
Миннебаева Рәмзия Рәүс кызы
Назмеева Алия Шамиль кызы

Яр Чаллы
2022 ел

**Эчтәлек**

1.Максатлар бүлеге.....................................................................................................................3
1.1.«Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы турында гомуми белешмә..........................................4
1.2.Төркем турында белешмә......................................................................................................4
1.3.Программаның максатлары һәм бурычлары .....................................................................5
1.4.Программага хас үзенчәлекләр ...........................................................................................5
1.5.Уртанчылар төркеме эшчәнлегенең юнәлеше.....................................................................9

2.Эчтәлек бүлеге.........................................................................................................................9
2.1.Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары ..............................................................................................9
2.2. 2 яшьтән алып мәктәп яшенә кадәрге балаларның үсеш юнәлешләренә туры килгән белем бирү эшчәнлеге.....................................................................................................9
2.3.Психологик-педагогик эш эчтәлеге
2.3.1.«Социаль-коммуникатив үсеш» белем бирү өлкәсе.....................................................9
2.3.2.«Танып-белү үсеше» белем бирү өлкәсе…………….....................................................14
2.3.3.«Сөйләм үсеше» белем бирү өлкәсе…………......……………........................... ..24
2.3.4.«Сәнгати-эстетик үсеш» белем бирү өлкәсе……………………………….............35
2.3.5.«Физик үсеш» белем бирү өлкәсе………………………...........................…...35
2.4.Ата-аналар белән эш..............................................................................................................40

3.Оештыру бүлеге......................................................................................................................41
3.1.Көндәлек режим.....................................................................................................................41
3.2.Методик программа белән тәэмин ителеш .......................................................................42
3.3.Предметлы тирәлек мохитен үстерү....................................................................................43
3.4.Материаль-техник тәэмин ителеш........................................................................................45

Кушымта
Кушымта 1. Балаларның яшь үзенчәлекләре ..........................................................................46
Кушымта 2. Белем бирү эшчәнлегенең тематикасы...............................................................50
Кушымта 3. Белем бирү эшчәнлеге челтәре ..........................................................................51
Кушымта 4. Сәламәтләндерү чаралары ..................................................................................52

## 1. Максатлар бүлеге

Бу программа ФДББСна нигезләнеп эшләнгән Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге «Туганнан алып мәктәпкәчә» төп белем бирү программасына һәм балалар бакчасының төп гомуми белем бирү программасына таянып төзелде.

**Эш программасы түбәндәге норматив документларга таянып төзелде:**

1. Федеральный закон от 29.12.2012 №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»с изменениями и дополнениями от 14.07.2022 №298, №299, №300
2. Федеральный закон от 03.08.2018 №317-ФЗ «О внесении изменений в статьи 11 и 14 Федерального закона «Об образовании в Российской Федерации»;
3. Комментарии к ФГОС дошкольного образования Минобрнауки России, Департамента общего образования от 28.02.2014 г. №08-249;
4. Профессиональным стандартом "Педагог (педагогическая деятельность в сфере дошкольного, начального, основного и среднего общего образования) (воспитатель, учитель)", утвержденного приказом Минтруда и Соцзащиты РФ № 544н от 18 октября 2013 г. (с изм. на 5.08.2016г);
5. СанПиН 2.4.3648-20 от 28 сентября 2020 г «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодёжи»;
6. СанПиН 2.3/2.4.3590-20 "Санитарно-эпидемиологические требования к организации общественного питания населения" от 27 октября 2020 г. № 32;
7. СанПиН 1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или) безвредности для человека факторов среды обитания» от 28.01.2021 № 2;
8. Санитарно-эпидемиологические правила СП 3.1/2.4.3598-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации работы образовательных организаций и других объектов социальной инфраструктуры для детей и молодежи в условиях распространения новой короновирусной инфекции (COVID-19)», утвержденный постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 30 июня 2020 года №16.
9. Приказ Министерства просвещения РФ от 31.08.2020г. № 373 «Об утверждении Порядка организации и осуществления деятельности по ООП – образовательным программам ДО»;
10. Методическими рекомендациями Минобрнауки «О разработке основной общеобразовательной программы дошкольного образования» от 21 октября 2010 года, № 03-248;
11. Закон Республики Татарстан «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» от 08.07.1992 №1560-XII (изменения и дополнения от 27.04.2017 г. №27-ЗРТ);
12. Закон Республики Татарстан «Об образовании» от 22.07.2013 г. №68-ЗРТ (принят Государственным Советом 28.06.2013 г.);
13. Устав муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения города Набережные Челны «Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по познавательно-речевому направлению развития детей № 49 «Гульназ», постановление от 22 сентября 2017 г. № 5633;
14. Примерная общеобразовательная программа дошкольного образования «От рождения до школы» под редакцией Н.Е.Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой, 2020 г.

15. «Основная общеобразовательная программа МБДОУ «Детский сад № 49 «Гульназ», приказ № 192 от 31 августа 2020 года.

## 1.1. Гомуми белешмә

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының атамасы:**

«Гөлназ» 49 нчы балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү оешмасы.

**Кыскача атамасы:** «Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы МБМББУ.

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының адресы:**

субъект РФ:Татарстан Республикасы

индекс: 423828

торак пункты: Яр Чаллы шәһәре

урам:Шамил Усманов

йорт: 133

шәһәрнең федераль телефон коды: (8552) телефон: 42-65-92

факс: 42-65-92 e-mail: det.sad49@mail.ru

сайт: https://edu.tatar.ru/n_chelny/page92698.htm

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының җитәкчесе:**

Габидуллина Эльза Сагил кызы

**Балалар бакчасы эшчәнлегенең юнәлеше:**

1.Танып белү-сөйләм үсеше, социаль-шәхси үсеш, физик үсеш, нәфис-нәфәсәти үсеш.

2.Мәктәптә укырга әзерләү (логик фикерләү, уку грамотасы...)

3.Сәламәтләндерү һәм авырулардан профилактика чаралары.

Балалар бакчасы 5 көнлек эш атнасында 6.00-18.00 сәгатькә кадәр эшли.

## 1.2. Төркем турында белешмә

**Төркемнең составы**

| №гр | Яше | Саны | Малайлар | Кызлар |
|---|---|---|---|---|
| 8 | 1-2 | 7 | 2 | 5 |

Балаларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, тәрбия һәм белем бирү процессының сыйфатын яхшырту максатында балалар бакчасы үз алдына түбәндәге бурычларны куя:

1. Балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.

2. Балаларга тәрбия һәм белем бирү сыйфатын камилләштерү максатыннан чыгып, федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) таянып, алдынгы педагогик тәҗрибәләргә нигезләнеп, педагогларның һөнәри осталыгын үстерү һәм тәрбия-өйрәтү процессында информацион-компьютер технологияләрен куллану.

3. Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек. Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы элемтәне халык педагогикасына, алдынгы гаилә тәҗрибәсенә таянып ныгыту, милли рухта мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтү.

4. “Татарстан Республикасы халыклары телләре” турындагы законны тормышка ашыруда яңа алымнарны куллану һәм укыту-методик комплекты аша балаларның сөйләмен сыйфатлы камилллләштерүне дәвам итү

Балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен түбәндәге кабинетлар эшләп килә: татар теле кабинеты, музыка һәм физкультура залы.

## 1.3 Программаның төп максатлары һәм бурычлары

**Эш программасының максаты:** балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып мәктәпкәчә яшьтәге балаларны физик, интеллектуаль, шәхси сыйфатларын үстерү.

**Эш программасының бурычлары:**

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, иректе белем бирү, мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче әһәмияткә ия:

- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү);
- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмалары һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә оешма тормышында катнашуын тәэмин итү;
- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау;
- региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

Эш программасының төп фикере - укыту, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау белән бергә баланың шәхесен үстерү.

**Эш программасының күрсәткече:**

*белем өлкәләрен интеграцияләү нигезендә тулы педагогик процессны төзү;
*балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып төп юнәлешләр – физик, социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти үсеш юнәлешләре буенча төрлеяклап үстерү;
*балаларның иҗади сәләтен ачу, сәләтлеләрне табу, шәхси үстерү өчен яңа технологияләр куллану;
*балаларның мөмкинчелегеннән, кызыксынучанлыгыннан, сорауларыннан чыгып төрле төр эшчәнлекләрне үстерү;
*эчтәлекле аралашуга, сөйләшүгә төзелгән шәхси һәм төркем белән эшчәнлекләр оештыру;
*балага эшчәнлектә үзен күрсәтү, эш эчтәлеген, эш төрләрен, эштә иптәш сайлау хокукы бирү.

## 1.4 Программага хас үзенчәлекләр

***Бала шәхесен үстерүгә юнәлгәнлек***

Программаның өстенлеге — иректе, үз-үзенә ышанган, актив тормыш позициясенә ия, тормыштагы төрле хәлләрдән чыгу юлларын табуга иҗади килергә омтылган, үз фикере булган һәм аны яклый белә торган кеше тәрбияләү.

***Программаның патриотик юнәлгәнлеге***

Программада балаларда Туган илгә карата мәхәббәт, патриотик хисләр, Ватанның казанышлары белән горурлану, Россиянең героик үткәне һәм бәхетле киләчәге булган күпмилләтле бөек ил икәнлегенә ышаныч тәрбияләүгә зур игътибар бирелә.

***Әхлакый тәрбиягә, традицион кыйммәтләрне яклауга юнәлгәнлек***

Ата-анага мәхәббәт, өлкәннәргә ихтирам, кечкенәләргә, олы яшьтәге кешеләргә карата кайгыртучан мөнәсәбәт кебек традицион кыйммәтләргә хөрмәт тәрбияләү; традицион гендер күзаллаулары булдыру; балаларның үз гамәлләрендә уңай үрнәккә ияру омтылышын

тәрбияләү. Алга таба укуны дәвам итү максатын куя Программа балаларда танып белү кызыксынучанлыгын үстерүгә, белем алу омтылышына, алга таба бөтен тормышы буена укуга (мәктәптә, институтта һ.б.) карата уңай мотивациягә; барлык кешеләргә дә белем алырга кирәклекне аңлауга юнәлтелгән. Белем алуга карата аны иң мөһим тормыш кыйммәтләренең берсе итеп карауны формалаштыру.

***Балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлгәнлек***

Программа тәрбиячеләр алдына куя торган төп бурычларның берсе — балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларда сәламәт яшәү рәвеше турында элементар күзаллаулар булдыру, уңай гадәтләр, шул исәптән дөрес туклану гадәте, хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ тәрбияләү.

***Баланың индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алуга юнәлгәнлек***

Программа һәрбер баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән, аңа исә тормыш эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрендә дә (көндәлек режимны баланың индивидуаль үзенчәлекләренә якынайту һ.б.), бала белән үзара аралашу формаларында һәм ысулларында да (аның индивидуальлегенә карата хөрмәт, эмоциональ халәтләренә игътибарлылык, үз-үзенә ихтирамлылык хисләрен яклау һ.б. ш.) балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу хисабына ирешелә.

***Тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән үзара бәйләнеш***

Программа гаиләнең уникаль тәрбия институты буларак кыйммәтен һәм тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы һәм тыгыз мөнәсәбәтләр булдыру кирәклеген ассызыклый. «Балалар бакчасының гаилә белән бәйләнешы» бүлегендә тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары белән төп эшләү формалары тасвирлана, аларны куллану педагогларга мәктәпкәчә белем бирүнең гомуми мәгариф программасын уңышлы гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә. Бала белән өйдә шөгыльләнү өчен кулланмалар — «Җиде Гном мәктәбе» сериясеннән китаплар белән тәэмин ителү Программаның мөһим өстенлеге булып тора.

## ПРОГРАММАНЫ ҮЗЛӘШТЕРҮНЕҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘРЕ
### Максат ориентирлары

Мәктәпкәчә балачакның үзгәлеге (бала үсешенең сыгылмалылыгы, аның үсеш вариантларының төрлелеге, аның табигыйлеге һәм нәрсәгә дә булса бәйле булуы) мәктәпкәчә яшьтәге баладан конкрет белем бирү нәтиҗәләренә ирешүне таләп итәргә мөмкинлек бирми һәм мәгариф программасын үзләштерү нәтиҗәләрен максат ориентирлары рәвешендә билгеләү зарурлыгын шарт итеп куя. Мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББСнда күрсәтелгән максат ориентирларын баланың ирешергә мөмкин булган казанышларының социаль-норматив сыйфатламалары буларак карарга кирәк. Бу — педагоглар һәм ата-аналар өчен өлкәннәрнең тәрбия эшчәнлегенең юнәлешен билгеләүче ориентир.

**Сабыйлык чорында һәм кече яшьтә белем бирүнең максат ориентирлары**

• Бала әйләнә-тирә предметлар белән кызыксына һәм алар белән актив эшли; уенчыклар һәм башка предметлар белән эмоциональ эш итүгә тартыла, үз хәрәкәтләре нәтиҗәсендә нәрсәгәдер ирешүдә үзсүзлелек күрсәтергә омтыла.

• Предметларга карата махсус үзләштерелгән гамәлләр куллана, көнкүреш предметларының (кашык, тарак, карандаш һ.б.) кулланылышын белә һәм алардан файдалана ала. Үз-үзенә хезмәт күрсәтүнең иң гади күнекмәләренә ия; көнкүрештә һәм уенда мөстәкыйль булырга омтыла; пөхтәлек күнекмәләрен күрсәтә.

• Дорфалыкка, саранлыкка карата тискәре мөнәсәбәт белдерә.

• Элементар әдәплелек кагыйдәләрен үти (мөстәкыйль яисә искә төшереп, «рәхмәт», «исәнмесез», «хушыгыз», «хәерле төн» (гаиләдә, төркемдә) дип әйтә; бакчада, өйдә, урамда элементар үз-үзен тоту кагыйдәләре турында беренчел күзаллауларга ия һәм аларны үтәргә тырыша.

• Аралашуда актив сөйләмгә ия; сораулар һәм үтенечләр белән мөрәҗәгать итә ала, зурлар сөйләмен аңлый; әйләнә-тирәдәге предметлар һәм уенчыкларның исемнәрен белә. Сөйләм башка балалар белән аралашуда тулы канлы чарага әверелә. • Зурлар белән аралашырга омтыла, һәм хәрәкәтләрдә, һәм гамәлләрдә актив рәвештә аларга
охшарга тырыша; бала зурлар гамәлләрен кабатлап күрсәтә торган уеннар барлыкка килә. Зурлар тәкъдим иткән уенга эмоциональ тартыла, уен кагыйдәләрен кабул итә.

• Яшьтәшләре белән кызыксына; аларның эш-гамәлләрен күзәтә һәм аларга охшарга тырыша. Яшьтәшләре белән аларга комачауламый гына янәшә уйный белә. Зур булмаган төркемнәр белән уртак уеннарга карата кызыксыну күрсәтә.

• Әйләнә-тирә табигать дөньясы белән кызыксына, ел фасылларына кагылышлы күзәтүләрдә кызыксынып катнаша.

• Шигырьләргә, җырларга һәм әкиятләргә, рәсемнәр карауга кызыксыну белдерә, музыка тавышына хәрәкәтләр ясарга омтыла; төрле мәдәният һәм сәнгать әсәрләренә эмоциональ мөнәсәбәтен белдерә.

• Курчак театры геройлары гамәлләрен аңлап күзәтә; театральләштерелгән һәм сюжетлы-рольле уеннарда катнашырга теләк белдерә.

• Продуктив эшчәнлек белән (рәсем ясау, әвәләү, конструкцияләү, аппликация) кызыксына.

• Балага эре моторика хас, ул төрле төрдәге хәрәкәтләрне үзләштерергә омтыла (йөгерү, үрмәләү, атлап чыгу һ.б.). Гади эчтәлекле, катлаулы булмаган хәрәкәтле уеннарда кызыксынып катнаша.

Мәктәпкәчә белем бирүне төгәлләү этабында максат ориентирлары

• Бала төп мәдәни чараларны, эшчәнлек ысулларын үзләштерә, эшчәнлекнең төрле төрләрендә — уенда, аралашуда, танып белү-тикшеренү эшчәнлегендә, конструкцияләүдә һ.б да инициатива һәм мөстәкыйльлек күрсәтә; үзенә шөгыль төрен, уртак эшчәнлек буенча катнашучыларны сайлап алырга сәләтле.

• Бала дөньяга, хезмәтнең төрле төрләренә, башка кешеләргә һәм үз- үзенә карата уңай мөнәсәбәткә ия, аңа үзенең урынын белү хас; яшьтәшләре һәм зурлар белән актив аралаша, уртак уеннарда катнаша.

• Килешүләргә, башкаларның ихтыяҗлары һәм хисләре белән исәпләшергә, аларның уңышсызлыкларын бүлешергә һәм уңышларына сөенергә сәләтле, үз хисләрен, шул исәптән үзенә ышаныч хисен дөрес белдерә, каршылыкларны чишәргә тырыша. Төрле мәсьәләләр буенча үз позициясен аңлатырга һәм якларга сәләтле.

• Уртак эшчәнлектә хезмәттәшлеккә һәм лидерлык, һәм башкару функцияләрен дә үтәргә сәләтле.

• Барлык кешеләрнең дә, социаль чыгышлары, нинди этник төркемгә керүләренә, дини һәм башка инануларына, физик һәм психик үзенчәлекләренә карамастан, тигез икәнен аңлый.

• Башка кешеләргә карата эмпатиягә ия, мохтаҗларга ярдәмгә килергә әзер тора.

• Башкаларны тыңлый белә һәм башкаларның да үзен аңлауларына омтыла.

• Баланың хыялга бирелүе үсешкә ирешкән, ул эшчәнлекнең төрле төрләрендә, һәм барыннан да элек уенда, гамәлгә ашырыла; уенның төрле формаларын һәм төрләрен уйный белә, шартлы һәм чынбарлыктагы хәлләрне аера ала; төрле кагыйдәләрне һәм социаль нормаларны үтәргә сәләтле. Килеп туган төрле хәлләрне тотып ала һәм аларны дөрес бәяли белә.

• Бала сөйләм теленә шактый оста, үзенең уйларын һәм теләкләрен белдерә, сөйләмне үзенең уйларын, хисләрен һәм теләкләрен аңлату өчен, аралашу вакытында сөйләм тезмәләре төзү, сүзләрдә авазларны аерып карау өчен куллана ала, балада грамоталылыкның алшартлары формалаша.

• Балада эре һәм вак моторика үскән; ул хәрәкәтчән, түзем, төп хәрәкәтләрне ясый белә, үз хәрәкәтләрен тикшерә һәм алар белән идарә итә ала.

• Бала ихтыяр көчен җыярга сәләтле, эшчәнлекнең төрле төрләре вакытында социаль тәртип нормаларын һәм кагыйдәләрен үти ала, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләрдә иминлекне саклау тәртибе кагыйдәләрен һәм шәхси гигиена күнекмәләрен үти ала.

• Башланган эш өчен җаваплылык сизә.

• Кызыксынучанлык күрсәтә, өлкәннәргә һәм яшьтәшләренә сораулар бирә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре белән кызыксына, табигать күренешләренә һәм кешеләр кылган гамәлләргә карата мөстәкыйль рәвештә аңлатмалар табарга тырыша; күзәтергә, экспериментлар ясарга һәвәс. Үзе турында, табигый һәм үзе яшәгән социаль дөнья турында башлангыч белемнәргә ия, балалар әдәбияты әсәрләре белән таныш, тере табигать, табигать белеме, математика, тарих һ.б. өлкәләр буенча элементар күзаллаулары бар; эшчәнлекнең төрле төрләре буенча, үзенең белем һәм күнекмәләренә таянып, карарлар кабул итүгә сәләтле.

• Яңалыкны кабул итәргә әзер, ягъни белем алуга, алга таба мәктәптә, институтта укуга карата уңай мотивациягә омтылыш күрсәтә.

• Тормышка (аның төрле формаларында) хөрмәт белән карый һәм әйләнә-тирә мохит турында кайгырта.

• Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгына, халык сәнгате һәм профессиональ сәнгать әсәрләренә (музыкага, биюгә, театраль эшчәнлеккә, рәссамлык эшчәнлегенә һ.б.ш.) эмоциональ бәя бирә.

• Патриотик хисләр кичерә, үз иле, аның казанышлары белән горурлана, аның географик төрлелеге, күпмилләтлелеге, иң мөһим тарихи вакыйгалары хакында күзаллаулары бар.

• Үзе, гаилә, традицион гендер юнәлешләрен дә эченә алган традицион гаилә кыйммәтләре хакында беренчел күзаллауларга ия, үз җенесенә һәм капма-каршы җенескә карата ихтирамлы.

• Гомуми кабул ителгән элементар нормаларны үти, «нәрсә яхшы, нәрсә начар» булуы турында беренчел күзаллауларга ия, яхшы гамәлләр кылырга омтыла; өлкәннәрне хөрмәт итә һәм кечкенәләр турында кайгырта.

• Сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллауларга ия. Сәламәт яшәү рәвешен кыйммәт буларак кабул итә.

Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы МББ ФДББС белән ярашлы рәвештә максат ориентирлары турыдан-туры, шул исәптән педагогик диагностика (мониторинг) рәвешендә дә, бәяләүгә алынмый һәм аларны балаларның реаль казанышлары белән формаль чагыштыру өчен нигез була алмый. Алар балаларның әзерлегенә һәм белем бирү эшчәнлегенә карата кабул ителгән таләпләргә туры килә торган объектив бәяләмәнең асылы булып тормый. Программаны үзләштерү арадаш аттестацияләр һәм тәрбияләнүчеләрнең йомгаклау аттестациясен уздыру белән кушылып китми. МББнең ФДББСннан күренгәнчә, максат ориентирлары идарә итү бурычларын хәл иткәндә турыдан-туры нигез була алмыйлар. Әлеге бурычларга түбәндәгеләр керә:

• педагогик кадрларны аттестацияләү;

• белем бирүнең сыйфатын бәяләү;

• балаларның соңгы, шулай ук арадаш үсеш дәрәҗәсен, шул исәптән мониторинг кысаларында бәяләү (шул исәптән күзәтүгә яисә балаларның нәтиҗәгә ирешүен тикшерүнең башка ысулларына нигезләнгән методлар кулланып тестлар уздыру формасында).

### 1.5. 1 нче кечкенә нәниләр төркеме эшчәнлегенең юнәлеше.

Төркемдә белем бирү процессы комплекслы һәм яңа парциаль программалары кулланылып үткәрелә:

Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан мәктәпкә кадәр”төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү комплекслы программасы

Программа сөйләм телен үстерү бүлегеннән тыш тулы күләмдә кулланыла.

*Парциаль программа*

«Сөенеч – Радость познания» - төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы;

## 2. Эчтәлек бүлеге

### 2.1. Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары

Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларның сыйфатлы физик үсешен тәэмин итү.

Һәр баланың эмоциональ уңай халәтен саклауга булышу.

Үз вакытында гомуми хәрәкәтләр һәм кул хәрәкәтләре формалашуга, шуышырга һәм йөрергә өйрәнүгә ярдәм итү.

Баланың талчыгуын булдырмау.

Күрү һәм ишетү юнәлешләрен формалаштыру.

Сиземләү тәҗрибәсен баету.

Өлкән кешенең сүзләрен аңлау сәләтен үстерү һәм актив сөйләмгә ирешүгә әзерләү.

Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү процессына керешү омтылышларын хуплау.

Балаларның үзара татулыгына, якын кешеләренә карата аерым дустанә мөнәсәбәтенә булышлык итү.

Уенчыкларга, рәсемнәргә, музыкага, җырлауга карата кызыксыну уяту; баланың гади бию хәрәкәтләре башкарудагы активлыгына булышлык итү.

Һәр баланың үз яшенә туры килгән сәләтләрне үзләштерүенә актив ярдәм итү, алынган нәтиҗәләрне системалы рәвештә һәм дөрес анализлау.

### 2.2. 2 яшьтән алып мәктәп яшенә кадәрге балаларның үсеш юнәлешләренә туры килгән белем бирү эшчәнлеге

1–7 яшьлек балалар белән психологик-педагогик эш эчтәлеге «Социаль-коммуникатив үсеш», «Танып белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Сәнгати- эстетик үсеш», «Физик үсеш» белем бирү өлкәләре буенча бирелә. Эшнең эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның, аларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен искә алып, төрле яклап үсешенә юнәлтелгән. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатларын формалаштыру буенча психологик-педагогик эш бурычлары белем бирүнең һәрбер өлкәсенең үзгәлеген чагылдыра торган бурычлар белән, мәҗбүри психологик тәэмин итү белән беррәттән, барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү барышында интеграцияле хәл ителә. Бу очракта программаның мәгариф бурычларын хәл итү турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, режимлы моментлар барышында да — өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә дә, мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең мөстәкыйль эшчәнлегендә дә карала

### 2.3 Белем өлкәләре буенча комплекслы - тематик план

### 2.3.1. «СОЦИАЛЬ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ»

*Хезмәт*

***Аңлатма язуы***

«Хезмәт» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар халык әкиятләре ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллаулар формалаштыру. Баланың эш барышын татар шагыйрьләренең хезмәт турындагы шигырьләре белән бәйләү.

Балаларга аңлаешлы һөнәрләр (төзүче, электрик, сантехник һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлегенең мәгънәсе турында күзаллаулар формалаштыру. Хезмәт эшчәнлегенең төп бурычы булып тора. Бу бурычны тормышка ашыру түбәндәге мәсьәләләрне чишү аша башкарыла:

- зурлар хезмәте белән танышу, хезмәтнең җәмгыятькә кирәклеге һәм файдасы турында күзаллауларын формалаштыру һәм кеше хезмәтенә хөрмәт, хезмәтнең нәтиҗәсенә сак караш тәрбияләү;
- балаларның хезмәт эшчәнлеген оештыру, эш тәҗрибәсе , эшне оештыру, зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара уңай мөнәсәбәтләр урнаштыру күнекмәләрен камилләштерү.

***Комплекслы-тематик план***

| **Тема** | **Интеграция** |
|---|---|
| ***Сентябрь*** | |
| 1. Балалар бакчасы белән таныштыру, бакча шартларына ияләштерү.<br>2.Уенчыкларны, уен материалларын урыннарына куярга өйрәтү.<br>3.Өлкәннәр ярдәме белән киенү-чишенү күнекмәләрен үстерү, киемнәрне шкафка җыеп кую тәртибе белән танышу.<br>4. Шәхси әйберләр белән эш итәргә өйрәтү.<br>5. Мөстәкыйль хезмәт күрсәтү күнекмәсен үстерә бару. | **Җыр- бию**: Н.Гайсин сүзл., Н.Зарипова муз. “Балалар бакчасында “җырын тыңлау, балалар бакчасы шартларына ияләштерүдә балаларда уңай эмоция булдыру. Җ.Тәрҗеманов ”Йомшак су, йөгерек су”- үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәсен үстерү.<br>**Аралашу**: иптәшләре, тәрбияче һәм тәрбияче ярдәмчесе белән танышу,исемнәрне әйтергә һәм истә калдырырга өйрәнү.<br>**Сәламәтлек**: шәхси-гигиена таләпләрен үтәү теләге тудыру.<br>**Танып белү**: уен бүлмәсе һәм андагы махсус почмаклар белән танышу |
| ***Октябрь*** | |
| 1.Үз-үзеңә мөстәкыйль хезмәт күрсәтү күнекмәсен үстерү.<br>2. Өлкәннәр ярдәме белән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнүне дәвам итү.<br>3. Өлкәннәр ярдәме белән киенү-чишенү, киемнәрне шкафка җыеп кую тәртибе белән танышуны дәвам итү.<br>4. Тәрбияченең бүлмә гөлләрен карау-тәрбияләвен күзәтү аша, балаларда үсемлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү, тәрбиячегә булышасы килү теләге уяту.<br>5.Культура- гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудыру. | **Сәламәтлек**: үз – үзеңне һәрвакыт тәртиптә тотарга кирәклекне аңлату, шәхси гигиена таләпләрен үтәргә өйрәтү.<br>**Аралашу**: тәрбиячене һәм иптәшләрен тыңлый белергә өйрәнү.<br>**Танып белү**: балаларның ишетеп кабул итү, тыңлый белү осталыгын үстерү.<br>**Матур әд.уку**: З.Туфайлова “Ул зур”, үскән гөлләргә карата сакчыл караш, матурлыкка соклану тәрбияләү. |
| ***Ноябрь*** | |
| 1. Өлкәннәр ярдәме белән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен өйрәнүне дәвам итү.<br>2. Үзлектән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнү.<br>3. Уйнаганнан соң уенчыкларны җыеп, урыннарына куярга өйрәнү, уенчыкларга сак | **Матур әд.уку**: Ә.Бикч.”Туп-туп- тубыбыз”. Шигырь аша уенчыкларга сак караш тәрбияләргә өйрәнү.<br>**Аралашу**: бергәләп уйнау теләге тәрбиләү.<br>**Социальләштерү**: кушылган эшкә карата җаваплылык формалаштыру .<br>**Танып белү**: бүлмә гөлләрен карау, тәрбияләү хезмәте аша балаларны табигать |

| | |
|---|---|
| караш тәрбияләү.<br>4. Тәрбияченең бүлмә гөлләрен каравын-тәрбияләвен күзәтү: су сибү, тузанын сөртү, төпләрен йомшарту. | дөньясына җәлеп итү, кызыксынучанлыкларын үстерү. |
| ***Декабрь*** | |
| 1. Өлкәннәр ярдәме белән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен үстерү.<br>2. Үзлектән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнүне дәвам итү.<br>3.Һавада уйнаганнан соң өс-баш киемнәрен кагарга, бер-берсенә ярдәм итәргә, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәсен үстерергә өйрәнү.<br>4.Балаларның игътибарын ишегалдын җыештыручы хезмәтенә юнәлтү, балаларда бу төр хезмәт ияләренә хөрмәт, җыештыручыга булышасы килү теләге уяту. | **Аралашу**: балаларны үзара дус,тату булырга өндәү, тыныч сөйләшергә өйрәтү.<br>**Социальләштерү:** зурлар хезмәтенә хөрмәт,аларга ярдәм итәсе килү омтылышытәрб.<br>**Танып белү:** ишегалдын җыештыручы хезмәте б-нтанышу, кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнәрен формалаштыру.<br>**Матур әд.**: Г.Тукай “Гали белән кәҗә” шигырен уку: бер-берсенә карата кайгыртучанлык тәрбиләү. |
| ***Январь*** | |
| 1. Балаларны һәрвакыт үзеңнең тышкы кыяфәтеңне карап торырга, үзлектән, булган җитешсезлекне бетерергә өйр.<br>2. Зурлар ярдәме белән киемнәрне тәртиптә тоту күнекмәләрен формалаштыру (чистарту, киптерү).<br>3. Үзлектән бер-берсенә һәм өлкәннәргә ярдәм итү теләге уяту.<br>4.Балаларның игътибарын тәрбияче ярдәмчесенең нәрсә эшләвенә, ул эш-гамәлне ничек һәм ни өчен башкаруына юнәлтү. | **Социальләштерү**:балаларда игътибарлылык, үз-үзеңә таләпчәнлек тәрбияләү.<br>**Аралашу**: балаларың бер-берсенә карата мөгаләмәсендә дуслык, хөрмәт, ярдәмчеллек хисләре тәрбиләү.<br>**Танып белү**: тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән танышу, балаларда тәрбияче ярдәмчесенә булышасы килү теләге тәрбияләү. |
| ***Февраль*** | |
| 1. Үзлектән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү.<br>2. Тәрб. ярд. күзәтчелеге астында ашау алдыннан өстәлгә ипи тәлинкәләрен һәм салфетка савытларын куярга өйрәтү.<br>3. Балаларда тәрбияченең табигать почмагындагы хезмәтен күзәтү даирәсен киңәйтү (суган,чәчәк орлыклары утырту).<br>4. Дидактик уен «Гөлләргә ни булган?<br>5. Рәсемнәр карап, әтиләр башкарган хезмәт белән танышу. | **Танып белү**: өлкәннәрнең табигать почмагындагы гөлләрне карау-тәрбияләүләрен күзәтү, үсү шартлары белән танышу.<br>**Социальләштерү:** с/р уен элементлары формалаштыра башлау, әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту, илдә барган бәйрәмнәр белән танышып бару.<br>**Аралашу**: балаларны өлкәннәргә булышырга өйрәтү, иң гади хезмәт эшчәнлегендә катнашырга омтылыш тәрбияләү. |
| ***Март*** | |
| 1. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Өлкәннәр ярдәме белән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен системалаштыруны дәвам итү.<br>3. Тәрбияченең белем эшчәнлегенә кирәк яраклар әзерләвен күзәтү, иң гади дежурлык | **Танып белү**: әниләр һөнәренә кагылышлы рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, төрле һөнәрләр белән танышу, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү.<br>**Социальләштерү**: әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, әниләргә хөрмәт тәрбияләү, бәйрәмнәр белән танышу.<br>**Җыр тыңлау:** ”Рәхмәт әнием” Ә.Һадиева |

| | |
|---|---|
| вазыйфасын үтәү элементлары булдыруны дәвам итү.<br>4. Рәсемнәр карап, әниләр башкарган хезмәт белән танышу. | муз., А. Минһаҗев сүзләре.<br>**Аралашу**: тәрбияче хезмәте белән кызыксыну, катлаулы булмаган биремнәрне үтәү осталыгына ирешү. |
| ***Апрель*** | |
| 1.Төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен мөстәкыйльләштерә бару, башлаган эшне ахырына кадәр эшләргә өйрәнү.<br>2. Балалар бакчасы уен җирлегендә иң гади хезмәт эшчәнлегендә катнашырга омтылыш тәрбияләү: кипкән яфраклар, чыбык-чабыклар җыярга теләк белдерү, тәрбиячегә булышу.<br>3. Уен өчен кирәкле әйберләрне урамга алып чыгуда һәм ахырдан җыеп алып керүдә тәрбиячегә булышырга өйрәнү, балаларда хезмәткә җаваплы караш тәрбияләү.<br>4.С/р уеннар: "Сатучы", "Чәчтараш", "Пешекче"аша бу төр төр хезмәт ияләренең хезмәте белән танышу, эшкә җаваплы караш тәрбияләү. | **Аралашу**: балаларның зурлар һәм иптәшләре белән ирекле аралашуларына ирешү.<br>**Танып белү**: үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен һәм файдасын күрә белергә өйрәнү, гади хезмәт хәрәкәтләрен теләп башкарырга өйрәтү, эш кораллары белән танышу.<br>**Социальләштерү**: табигатьтә яз көне башкарыла торган хезмәт белән танышу. |
| ***Май*** | |
| 1. Үз үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Утырткан үсемлекләрне тәрбияләүгә кызыксынучанлык, хезмәткә булышасы килү теләге тәрбияләүне дәвам итү.<br>3. Зурлар хезмәте турында ( шофер, очучы, табиб, һ.б.) күзаллау булдыру.<br>4. Сюжетлы-рольле уеннар "Шофер", "Шифаханә", "Очучы" | **Танып белү**: үсемлекләрнең үсешен күзәтү, үсү шартлары бедән кызыксыну.<br>**Социальләштерү:** Һөнәр ияләре турында рәсемнәр карау,<br>тәрбияче ярдәме белән уеннарны рольләргә бүлергә өйрәнү.<br>**Җыр тыңлау**: "Мин шофёр" |

***Аңлатма язуы***

«Куркынычсызлык» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

***Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру***

Балаларны балалар бакчасында көндәлек режим һәм үз- үзләрен тотуның иң элементар кагыйдәләре белән, бүлмәдә хәвеф-хәтәрсез йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.

Үз тормышың куркынычсызлыгы нигезләре турында белемнәрне үзләштерү, саклык, сизгерлек хисе тәрбияләү.

Балаларны тормышта яңа, алар өчен гадәти булмаган очракларда, таныш булмаган кешеләр белән очрашканда үз- үзләрен дөрес тотарга өйрәтү.

***Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру***

Юл хәрәкәтендә светофорның кызыл, сары, яшел төсләренең урнашу тәртибе һәм мәгънәләре белән таныштыру. Светофор сигналы буенча хәрәкәт итәргә күнектерү.

Балаларны юнәлешләрне (алга - артка, өскә - аска, уңга - сулга) аерырга гына түгел, шулай ук күрсәтелгән юнәлештә йөрергә, үзеңә карата теге яки бу әйбернең торышын (миннән сул якта - өй, уңда - машина, алда - җәяүлеләр, артта - велосипедчы) билгеләргә өйрәтү.

Чагыштырмача хәрәкәт итү тизлеген (тиз, акрын) билгеләргә, транспорт чараларының (трамвай, автобус, янгын сүндерү машинасы, ашыгыч ярдәм машинасы һ. б.ның) тавыш сигналларын аерырга, тавыш чыганагының кайда булуын сиземләргә, кирәк очракта туктарга өйрәтү. Ишетү-хәрәкәт координациясен үстерү.

Кайбер җәмәгать транспортлары (троллейбус, автобус, трамвай, поезд, самолёт, теплоход һ. б.) турында күзаллауларны баету; маршрут транспорты (автобус, троллейбус, трамвай) тукталышы урыннарын билгеләү; «Автобус яки троллейбус тукталышы»н аңлатучы билге белән таныштыру. Җәмәгать транспортына утыру һәм аннан чыгу кагыйдәләренә игътибар итү.

Балаларга метрополитен, тимер юл, поезд, машинист хезмәте, тимер юлда һәм тимер юл транспортында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында сөйләү. Тимер юл макеты белән таныштыру.

Урамда үз-үзеңне тотуның иң элементар кагыйдәләрен (йөгермәү, кычкырмау, тротуар кырыеннан йөрмәү һ. б.) үтәүгә ирешү. Җөяүле юлы белән, «җәяүлеләр юлы» билгесе белән таныштыру; урамны кайда һәм ничек аркылы чыгу турында, велосипедта йөрү кагыйдәләре турында аңлату.

Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буенча, предметларны әйләнеп үтеп, өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәтүне дәвам итү. Үз хәрәкәтләре белән идарә итә белү, тормозга басып туктата алу күнекмәләрен үстерү. Спорт мәйданчыгында иркен ориентлаша белүне камилләштерү.

Транспорт чараларының охшаш һәм аермалы якларын табарга, билгеләнгән үзлекләре һәм функциональ үзенчәлекләре буенча чагыштырырга һәм төркемнәргә берләштерергә өйрәтү, алынган мәгълүматны гомумиләштерергә тырышуларын («Охшашны җый», «Оча, йөзә, йөри» һ. б.) хуплау.

Өлкәннәр хезмәте турындагы белемнәрен киңәйтү: троллейбус (автобус) йөртүче троллейбус (автобус) йөртә; кар җыйгыч машинаны йөртүче юлларны кардан чистарта; ЮХИДИ инспекторы юлларда автомобильләр хәрәкәтен җайга сала һ. б.; эш төрләре һәм эш максаты арасында бәйләнешне ачыкларга ярдәм итү.

Балаларның, сюжетлы-рольле уенда юлда имин йөрү кагыйдәләрен чагылдыру өчен, мөстәкыйль рәвештә пред- метлы-уенлы мохит тудыруларын, модульләргә уен мәгънәсе бирүләрен, образлы һәм техник уенчыкларны, аларны алыштыручы алмаш предметларны куллануларын хуплау.

Балаларны уен ситуацияләрендә шартлы уйдырманың максатын аңларга, коллективта уен кагыйдәләренә яраклашып эш итәргә, игътибарлы булырга, уен персонажларының (транспорт йөртүчеләр, җәяүлеләр, пассажирлар һ. б.) роль буенча хәрәкәтләрен төгәлрәк башкарырга, ишетү һәм күрү сигналларына, әйләнә-тирәдәге көтелмәгән үзгәрешләргә тиз җавап бирергә, мөстәкыйльлек күрсәтергә һәм мәйданда ориентлашырга өйрәтү.

Мөстәкыйль дидактик уеннарда балаларның алган тәҗрибәләрен файдалануга шартлар тудыру. Төрле характердагы ял итү уеннары оештыру; юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен әһәмиятле ситуацияләрне эченә алган уен-мавыгулар, курчак театры, сәхнәләштерелгән гади әсәрләр, уеннар өйрәнү.

Балаларда, шартлар буенча һәм үзләре уйлап тапканча, шәһәр (авыл) урамнары макетын төзү теләкләрен үстерү. Балаларны объектларның пространстводагы сурәтләмәләрен - озынлыкларын (биеклекләр, киңлекләрен) аера белү; деталь һәм аның өлешләренең урынын (өстән, астан, өстенә, астына һ. б.) билгеләүгә; объектларны (деталь һәм аның өлешләрен һ. б.ны) анализларга өйрәтү; тимер юллар, ике яклы хәрәкәт итү юллары, күперләр, гаражлар һ. б.төзүгә омтылышларын үстерү.

Балаларны табигать күренешләренә, тәүлектәге үзгәрешләргә һәм аларның әйләнә-тирәдә чагылышына (кич - урамда караңгы төшә - багана башларында фонарьлар яна, машиналар фараларын кабыза) игътибар итәргә өйрәтү.

Юлларда куркынычсыз йөрү кагыйдәләрен өйрәнү процессына кызыксыну уяту.

*Экологик аң алшартларын формалаштыру*

Балаларны хайваннар белән очрашканда сак булырга өйрәтү, агулы үсемлекләрнең үзлекләре турында кисәтү.

Кайбер куркыныч сыеклыклар, газсыман матдәләр, ут, зарарлы ашамлыклар турында, витаминнар, дару препаратларын күп күләмдә кабул итүнең куркынычлыгы турындагы күзаллауларын үстерү.

## 2.3.2. «ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ»белем бирү өлкәсе

***ӘЙЛӘНӘ – ТИРӘДӘ ОРИЕНТЛАШУНЫ КИҢӘЙТҮ***

### *Аңлатма язуы*

«Танып белү үсеше» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын Һәмакылныүстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларны әйләнә - тирәдәге предметларның исемнәре белән таныштыру эшен дәвам итү:уенчыклар, савыт- саба, өс киемнәре, аяк киемнәре, йорт җиһазлары, транспорт чаралары. Предметларның төсен, формасын, зурлыгын, нинди материалдан (кәгазь, агач, тукыма эшләнгән булуын әйтә белергә; таныш әйберләрне чагыштырырга (төрле башлыклар, бияләйләр, аяк киеме һ.б.); бертөсле, охшаш әйберләрне табарга (шундыйны ук тап, парын тап һ.б.) функцияләреннән (файдалану ысулыннан) чыгып төркемнәргә (чынаяктан чәй, җимеш суы эчәргә) өйрәтү.Балаларның предметлар белән эш- гамәлләр башкару ихтыяҗын тормышка ашырырга булышлык итү. Теге яки бу әйбернең ни өчен кирәк булуын, аларны ничек кулланырга мөмкинлеген аңлату.

**Гаилә.** Баланы узенең йортын,фатирын танырга; уз исемен һәм гаилә әгъзаларының исемнәрен әйтә белергә өйрәтү. Якыннарының хәленә керә белүчәнлек тәрбияләү (кызгану,ярдәм итү һ.б.).

Кеше яши торган торак төзелеше (шәһәрдә һәм авылда), йорт кирәк-яраклары турында күзаллаулар булдыру. Кеше кулы белән ясалган җайланмаларның төзелеше һәм билгеләнеше турында сораулар бирергә, һәр яңалык белән танышырга омтылыш тәрбияләү.

**Балалар бакчасы.** Үзләре йөргән балалар бакчасын танырга, төркем бүлмәсен табарга өйрәтү. Үз тәрбиячеләре, тәрбияче ярдәмчесе, балалар бакчасының башка хезмәткәрләренә карата ышану, ярату хисләре булдыру өчен шартлар тудыру.Яшьтәшләренә карата игътибарлы, ягымлы булырга өйрәтү.Башкалар белән сугышырга, аларга карата дорфа, тупас мөгамәләдә булырга ярамаганлыгын аңлату.Төркем бүлмәсендә, мәйданчыкта ориентлаша белергә өйрәтү;төп биналарны, корылмаларны (төркем бүлмәсе, баскыч, веранда,комлык һ.б.) әйтә белергә күнектерү.

**Туган ил.** Үзләре яши торган шәһәр (бистә, авыл), урам исемнәрен балаларның исләренә төшереп тору.

**Өлкәннәр хезмәте.** Балаларда якыннарының хезмәтенә карата кызыксынучанлык тәрбияләү. Кайбер эш төрләрен аңлап әйтергә өйрәтү (тәрбияче ярдәмчесе савыт-саба юа, бүлмә җыештыра, ашарга алып килә, сөлгеләрне алыштыра һ.б.).

**Экологик тәрбия.** Балаларда табигать белән кызыксынучанлык тәрбияләү: үсемлекләр (үлән, агач) турындагы күзаллауларын киңәйтү,бүлмә гөлләре белән таныштыру (яфракларын, чәчәкләрен күрсәтү), йорт хайваннарын (песи һәм песи балалары, эт һәм көчекләр һ.б.) күзәтү, йорт кошлары (әтәч,тавык,чебиләр һәм балалар бакчасындагы мәйданчыкка килгән кошлар (чыпчык,карга) белән таныштыру.

Үзләре яшәгән җирдә үскән кайбер яшелчә, җиләк – җимешләрне тышкы билгеләре һәм тәмнәренә карап аера белергә өйрәтү.

Балалар белән бергәләп табигатькүренешләрен күзәтү һәм аларның матурлыгын (кар бортекләре оча, яфраклар ява, күктә салават күпере күренде, гөлләр чәчәк ата һ.б. ) күрергә ойрәтү. Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында сөйләү.

***Комплекслы – тематик план***

| ай | атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | I | Йомшаккай бездә кунакта | 1) балаларның уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтү, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгын формалаштыру, уенчык исемнәре һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру;<br>2) тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләген үстерү;<br>3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, уенчык ларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | II | Йомшаккай тагын бездә кунакта | 1) уенчыкларны карарга һәм аерым өлеш ләрен билгеләргә өйрәтү; уенчыкларның исемен, өлешләрен әйтү, төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертү;<br>2) тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, кызыклы уенчыклар белән уйнаудан тәм табу, шатлык хисләре тәрбияләү. |
| | III | Тупны коткарабыз | 1) рәсемнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне һәм фразаларны актив кабатлауларын үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | IV | Юыну бүлмәсен карау | 1) балаларны юыну бүлмәсендәге предметлар (сабын, сөлге, кран, су, теш щёткасы, теш пастасы) белән таныштыру, функциональ билгеләнешләре турындагы күзаллауларын ачыклау;<br>2) сүзләрне төрле грамматик формаларда (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.) куллану осталыгына ирешү, балаларның сөйләм активлыгын, инициативасын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү омтылышы тәрбияләү. |
| Октябрь | I | Көзге табигать | 1) балаларның көз (табигатьтәге үзгәрешләр, кешеләрнең киеме һ.б.) турында гади күзаллауларын формалаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерү;<br>3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| | II | Җиләк-җимешләр | 1) тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләрне аерырга өйрәтү, җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турында күзаллауларын киңәйтү, җиләк-җимешләрнең исемнәре һәм аларның билгеләрен белдерә торган сүзләрхисабына балаларның |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сүз байлыгын үстерү;<br>2) балаларның игътибарын, үзләштерү, кабул итү<br>һәм сенсор тою сәләтен, сорауларга җавап бирү<br>осталыгын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белергәгадәт лән дерү, әйләнә-тирә табигать объектларына кызыксыну тәрбияләү. |
| | III | Безнең Алсу"сериясенн ән рәсем карау | 1) рәсемдәге предметларны таный һәм исемен әйтә белергә, рәсем эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен ишетә һәм үти белүләренә<br>ирешү;<br>3) рәс емне кызыксынып карау теләге тәрбияләү. |
| ноябрь | IV | Яшелчәләр: помидор,кыяр, кишер белән таныштыру | 1) балаларның помидор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгыту; помидор, кыяр, кишернең форма, төс, тәм үзенчәлекләре (кызыл, йомшак, шома, тәмле, сусыл, хуш исле, шар формасындагы помидор; яшел, каты, шома, кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер) белән таныштыру;<br>2) балаларның сенсор тою сәләтен, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү осталыкларын үстерү;<br>3) балаларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләндерү, зурлар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. |
| | V | Рәсемдәге кошларны карау | 1) балаларда күгәрчен, саескан турында гомуми күзаллаулар булдыру, кошларга карата кызыксыну уяту;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген һәм сүз байлыгын үстерү;<br>3) кошларга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| | I | "Көз" (йогаклау чарасы | 1) балаларның көз турындагы белем нәрен (яфраклар саргая, сары яфраклар , яфраклар коела, яңгырлар күп ява, кешеләр җылы кием нәрен кияләр) ныгыту, тәр бияче сорауларына дөрес җавап бирергә, рәсем ясаганда, буяуны кәгазь битенә дөрес һәм тигез төше рергә өйрәтү, төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту;<br>2) балаларның актив сөйләмен, ишетеп кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, рәсем ясарга кызыксындыру;<br>3) көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| | II | Минем исемем бар | 1) баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтү, исемнәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү;<br>2) тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, кайберфразаларны (Минем исемем — Алсу) кабатларга күнектерү, хәтерне, игътибарны үстерү;<br>3) балаларда зурларга һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | Бу- мин | 1) организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштыру, үзләрен бербөтенитеп кабул итәргә өйрәтү, гәүдә өлешләре турында белемнәрне ачыклау һәм ныгыту;<br>2) гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәч, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>3) үзеңне, гәүдә өлешләреңне ярату, игътибарлы булу, культура-гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудыру. |
| | IV | Яраткан уен бүлмәбез | 1)Балаларны балалар бакчасы шартларына ияләндерүне дәвам итү, төркемдәге уен бүлмәсе, андагы махсус почмаклар белән таныштыру, “һәр әйбернең үз урыны” дигән төшенчәне аңлату һәм ныгыту;<br>2)Сүзләрне һәм фразаларны ачык әйтүләренә ирешү, сүз байлыгын үстерү; |
| | I | “КамАЗ” мшинасы | 1) балаларны КамАЗ машинасын һәм аның өлеш ләрен танырга, исемен әйтергә өйрәтү; уенның сүз ләренә туры китереп, хәрәкәтләр ясау осталыгы булдыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, эмоциональлеген үстерү;<br>3) балаларда йөк транспортына, өлкәннәр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. |
| | II | Гирлянда | 1) балаларга гирлянда турында башлангыч белемнәр бирү, электр тогы турындагы күз ал лауларын ныгыту, кызыл, яшел, сары төсләрне таный һәм аера белергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кызыксынучанлыгын, шатлык хисләрен үстерү, сүз байлыгын киңәйтү;<br>3) күмәк эшчәнлектә катнашу теләге тәрбияләү. |
| | III | Яшел чыршы | 1) балалар белән бергәләп чыршыны карау, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм баету;<br>2) балаларның «Яңа ел бәйрәме» темасы буенча сүз байлыгын активлаштыру, тәрбияче соравына җавап бирү осталыгын, игътибарын, күзәтүчән леген, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) матурлыкны күрә һәм аңа соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | IV | Безнең урам | 1)балаларны урам белән таныштыру;<br>2)игътибарын арттыру;<br>3)урамга соклану хисе тәрбияләү. |
| январь | I | Күгәрченнәр, чыпчыклар – безнең нәни кошчыклар | 1) мәйданчыктагы җимлеккә килгән кошларны күзәтү, исемнәрен әйтү; гөр-гөр, чырык-чырык, кар - кар аваз ияртем нәрен ачык әйтергә күнектерү; томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырылдый, җитез, өлгер сүзләре хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | II | Йорт хайваннары | 1) балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | әйтергә күнектерү;<br>2) сүзлекне баету, тәрбияченең сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбия ләү. |
| | III | Җәнлекләр урманда яшиләр | 1) җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтү һәм ныгыту, җәнлекләрне таный һәм исем нәрен атый белергә өйрәтү;<br>2) балаларның диалогик сөйләмен активлаштыру, фикерләвен, мөстәкыйльлеген үстерү;<br>3) җәнлекләр белән кызыксындыру. |
| Февраль | IV | Алсу бәйрәмгә җыена | 1) өс киемнәре, аларның төсе һәм материалы белән танышуны дәвам итү, сүзлекне активлаштыру: ефәк, ак чәчәкле кебек яңа сүзләр кертү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сорауларны ишетү, аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыкларын үстерү;<br>3) курчаклар белән уйнарга теләк уяту, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | I | Кибеткә барабыз | 1) бәйләнешле сөйләмне устерү,өйрәнелгән сүзләрне актив сүзлеккә кертү.<br>2) кибеттә үз-үзеңне әдәпле тотуның иң гади кагыйдәләрен үтәргә теләк тудыру. |
| | II | Транспорт төрләре белән таныштыру | 1) балаларны транспорт төрләрен таный белергә, исемнәрен әйтергә өйрәтү.<br>2) балаларда күзаллау сәләтен үстеру.<br>3) транспортта барганда кычкырып сөйләшергә ярамаганлыгын аңлату. |
| | III | Безнең әтиләр | 1) балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәр карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-гамәлләрне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүз байлыгын үстерү;<br>3) төрле һөнәр кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну уяту. |
| | IV | Безнең әниләр | 1) балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы сюжетлы кечкенә рәсемнәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү, эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү; |
| март | I | Кеше әгъзалары | 1) кеше әгъзаларын аңлата торган сүзләрне кулланышка кертү<br>2) әйе,юк сүзләрен сөйләмдә ныгыту.<br>3) балаларда чисталыкка омтылыш тәрбияләү. |
| | II | Матрёшкалар | 1) уенчыкның (матрёшканың) исемен дөрес әйтергә,төсендә һәм зурлыгында булган аермалыкларны күрә белергә күнектерү; зур, кечкенә, сарафан, яулык сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) балаларда халык уенчыкларына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | III | Яз, яз килә | 1) балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү;<br>3) табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |
| | IV | Безнең апа” | 1) тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш-хәрәкәтләрне әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әйләнә-тирәдәге кешеләр хезмәтенә кызыксыну тәрбияләү. |
| апрель | I | Урманда яз | 1) балаларга язгы күренешләр турында башлангыч белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү;<br>3) табигатьтәге язгы күренешләр белән кызыксындыру. |
| | II | Тузганак чәчәген карау. | 1) балаларны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итү, тузганак чәчәген күрсәтү, аны танырга, исемен әйтергә, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча аера белергә өйрәтү; сүз байлыгын киңәйтү; тузганак, чәчәк, сабак сүзләрен сөйләмдә активлаштыру;<br>2) балаларның сенсор тою һәм кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уяту, үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләү. |
| | III | Сыерчыклар, карлыгачлар килде (рәсемнәр карау). | 1) балаларны үзләренә таныш кошларны рәсемнән танырга, исем нәрен әйтергә өйрәтү; балаларның сүз байлыгын арттыру, сүзлеккә сыерчык, сыерчык оясы, карлыгач сүзләрен кертү;<br>2) игътибарны, күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) кошлар һәм табигать белән кызыксынуларына ирешү, кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | IV | Песиле тал бөреләрен карау | 1) балаларны песиле тал, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштыру, табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итү, сүз байлыгын киңәйтү һәм песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш исле сүзләре исәбенә сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, күзәтүчәнлеген, хәтерен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) табигать белән кызыксыну, табигать матурлыгына соклану хисләре тәр бияләү. |
| | V | Балалар тавык һәм чебиләр ашата | 1) балаларны рәсемне карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшлә рен тыңларга өйрәтүне дәвам итү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2) сөйләмне томшык, тавык, чебиләр, табак сүзләре хисабына баету, игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерү;<br>3) йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү. |
| май | I | Йорт хайваннары | 1) балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтү, хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен әйтергә күнектерү;<br>2) сүзлекне баету, тәрбиячененң сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләген үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбия ләү. |
| | II | Экология сукмагы буенча сәяхәт | 1) ”Яз” темасы караган сүзләрне активлаштыру, сөйләмдә ныгыту.<br>2) тирә-юньдәге усемлекләр турындагыкүзаллауларын ныгыту.<br>3) балаларда табигать белән кызыксынучанлык һәм аңа сакчыл караш тәрбияләү. |
| | III | Ком һәм аның үзлекләре | 1) балаларны комны тикшерергә (комны учка алырга, йомарларга һәм сибәргә), төсе буенча аның дымлылыгын билгеләргә өйрәтү;<br>2) коры, дымлы, юеш, сибелүчән, сибелә, әвәләү сүзләре хисабына балаларның сүз байлыгын киңәйтү, игътибарын,<br>сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) ком белән уйнарга кызыксындыру. |
| | IV | Чәчәкләр | 1)балаларның чәчәкләр турында белемнәрен арттыру;<br>2)диалогик сөйләм күнекмәләрен булдыру;<br>3)соклана белү хисләре тәрбияләү. |

***Комплекслы – тематик план***

***ДИДАКТИК МАТЕРИАЛЛАР БЕЛӘН УЕН***

***Аңлатма язуы***

Дидактик уеннар булыша :

- танып-белү һәм акыл сәләтләрен үстерү: яңа белемнәр алу, аларны гомумиләштерү һәм ныгыту, аларда булган Табигать, үсемлекләр, хайваннар турында күзаллауларны киңәйтү; - хәтер, игътибар, күзәтчелекне үстерү ;

- балалар сөйләмен үстерү: сүзлекне тулыландыру һәм активлаштыру,үз фикереңне әйтә белү, фикереңне әйтә белү, фикерләү. - мәктәпкәчә яшьтәге баланың социаль-әхлакый үсеше : мондый уенда балалар, өлкәннәр, тере һәм тере табигать объектлары арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне аңлыйлар, анда бала яшьтәшләренә сизгер мөнәсәбәт күрсәтә, гадел булырга, кирәк булганда бирешергә өйрәнә, хис итәргә өйрәнә һ. б.

Дидактик уен структурасын төп һәм өстәмә компонентлар тәшкил итә. Төп компонентларга дидактик бурыч, уен гамәлләре, уен кагыйдәләре, нәтиҗә һәм дидактик материал керә. Өстәмә компонентларга: сюжет һәм роле.

Дидактик бурычны билгеләгәндә, иң беренче чиратта, балаларның нинди белемнәре, күзаллаулары үзләштерелергә, нинди акыллы операцияләр ясарга тиешлеген, нинди акыллы операцияләрне үстерергә тиешлеген, әлеге уен чаралары белән нинди шәхес сыйфатларын (намуслылык, тыйнаклык, күзәтүчәнлек, үҗәтлек һ.б.) булдырырга кирәк.

Һәр дидактик уенда үз укыту бурычы бар, бу бер уенны икенчесеннән аерып тора. Дидактик бурычны билгеләгәндә аның эчтәлегендә кабатланмаска кирәк. Тәрбияче алдан ук белергә һәм дидактиканы билгеләргә тиеш

Уен кагыйдәләренең төп максаты-балаларның үз-үзләрен тотышын оештыру. Кагыйдәләрне хәл итәргә, тыюга, балаларга уенга нәрсә дә булса кушарга, уенны кызыклы, киеренке итә ала.

Уенда кагыйдәләрне үтәү балаларда билгеле бер ихтыяр көче, яшьтәшләре белән мөрәҗәгать итә белү, тискәре нәтиҗә аркасында барлыкка килгән тискәре эмоцияләрне җиңә белүне таләп итә. Уен кагыйдәләрен билгеләп, балаларны биремне үтәүдән шатлык алган шартларга кую мөһим.

| | |
|---|---|
| Сентябрь | “Шарны тишеккә этеп керт”<br>“Кастрюльнең капачын тап” |
| Октябрь | “Пирамиданы җый”<br>“Шарларны таякка кертәбез” |
| Ноябрь | “Борчакны бушат”<br>“Камканы бизә” |
| Декабрь | “Тармада нәрсә ята”<br>“Пирамиданы җый”<br>“Шакмак белән шарларны җый” |
| Январь | “Әтәч” ике пирамида”<br>“Погремушканы җый” |
| Февраль | “Уенчыкларны җый”<br>“Ярмаларны калак кучер” |
| Март | “Мозайка”<br>“Стаканардан пирамида, бәләкәйдән зурга” |
| Апрель | “Таякчыкларны эт”<br>“Суны бушатабыз ” |
| Май | “Зур һәм бәләкәй түгәрәкләр”<br>“Матрешкалар”<br>“Баранки” |

## *Комплекслы – тематик план*

### *ТӨЗҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ БЕЛӘН УЕН*

### *Аңлатма язуы*

Материалларының аерым детальләре (шакмак, кирпич, түбә (өчкырлы призма), цилиндр, такта (пластина) белән таныштыру. Балаларның иң гади конструкцияләү осталыкларын үстерү.

Үрнәк буенча гади генә корылмалар төзи белүләренә ирешү, мөстәкыйль рәвештә нәрсә дә булса төзү теләкләрен хуплау.

Корылмаларның үлчәмнәренә туры китереп, (кечкенә машиналар өчен кечкенә гараңлар), өстәмә сюжетлы уенчыклар кулланырга, өлкәннәр белән бергәләп кечкенә манаралар һәм өйләр, машиналар төзергә өйрәтү.

Җәйге чорда төзелеш уеннарында табигать материалларын кулланырга өйрәтү.

Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр:

- Төзелеш материаллары детальләренең төп формаларын белү;
- Күпчелек формаларны кулланып, өлкәннәр ярдәме белән төрле корылмалар төзү.
- Корылмалары белән уеннар оештырырга өйрәтү.

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| Сентябрь. Тема: «Әйдәгез танышабыз!” | I | “Әтәчкә өй” | Балаларны төзү материаллары һәм алардан төрле корылмалар төзергә мөмкин булуы белән кызыксындыру. Геометрик фигуралар: шакмак, призма белән таныштыру. |
| | II | “Эт өчен өй” | Төзү материаллары белән таныштыруны дәвам итү, төзегән әйбергә игътибар тупларга һәм эчке кичерешләрне сүз белән әйтә белергә өйрәтү. |
| | III | “Куянга өй” | Геометрик фигуралар: зур һәм кечкенә шакмаклар, призма белән таныштыруны дәвам итү, төзеп һәм уйнап күрсәткәндә тәрбиячегә булышырга теләк тудыру. |
| | IV | “Алсу өчен урындык” | Төзү материаллары: призма һәм шакмак белән таныштыруныдәвам итү, геометрик фигуралар белән гади төзелешләр башкарырга теләк тудыру. |
| Октябрь. Тема: “Көзне кунакка чакырабыз” | I | “Ике зәңгәр шакмактан башня төзү” | Төзү материаллары: кирпич һәм шакмак белән танышу, зәңгәр төсне аерырга өйрәтү. |
| | II | “Өч сары шакмак белән башня төзү” | Шакмак һәм призма кулланып төзи белү осталыгын камилләштерү, сары төсне танырга, төзү алымын (шакмак өстенә шакмак кую) өйрәтү. |
| | III | “Дүрт яшел кирпичтән башня төзү” | Кирпичләр һәм призма кулланып төзи белү осталыгын камилләштерү, яшел төсне танырга, төзү алымын (шакмак өстенә шакмак кую) өйрәтү. |
| | IV | “Дүрт кызыл кирпичтән башня төзү” | Кирпичләр һәм призма кулланып төзи белү осталыгын камилләштерү, кызыл төсне танырга, төзү алымын (шакмак өстенә шакмак кую) өйрәтү. |
| Ноябрь. Тема: «Урман серләре” тТема: “Урман серләре” | I | “Шакмак һәм кирпичләрдән өстәл белән урындык” | Берьюлы ике төрле төзү материалы (шакмак һәм кирпич) белән эшләргә, сары төсне танырга һәм әйтә белергә өйрәтү. |
| | II | “Яшел өстәл һәм ике сары урындык” | Берьюлы ике төрле һәм ике төсле төзү материалы (шакмак һәм кирпич) белән эшләргә, тйзү детальләрен формасы һәм төсе буенча  аерырга, танырга өйрәтү. |
| | III | “Өстәл һәм зәңгәр кресло” | Төзү материалларын формасы һәм төсе буенча аера белергә өйрәтү. |
| | IV | “Төрле төстәге өстәл һәм урындык” | Корылмаларны төсе буенча аера белергә өйрәтү. |
| Декаб | | “Төрле төсле юл” | Кирпичләр белән эш итә белүне |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | ныгыту, форма һәм төсләрне аерырга өйрәтү. |
| | II | “Тар, сары юл” | Төзү материалларын тар ягы белән куеп эшләргә, сары төсне танырга һәм әйтергә өйрәтү. |
| | III | “Киң кызыл юл» | Төзү материалларын киң ягы белән куеп эшләргә, кызыл төсне танырга һәм әйтергә өйрәтү. |
| | IV | “Бер үк төстән туп һәм юл» | Төсләре буенча төзү детальләрен танырга һәм әйтә белергә өйрәтү. |
| Гыйнвар. Тема: “Кышкыуеннар” | I | “Койма” | Үрнәктән файдаланып, төзү материалын озын ягына кую алымын кулланып, эшләргә өйрәнү. |
| | II | “Койма” | Кирпичне тар ягы белән кую алымын кулланып эшләргә өйрәнү. |
| | III | “Шакмак һәм кирпичләрдән койма” | Төзү материалларын чиратлаштырып куеп төзергә өйрәтү. |
| | IV | “Зәңгәр шакмак һәм кызыл кирпичтән койма” | Зурлыгы һәм төсе төрле булган детальләрдән койма төзи белү осталыгын үстерү, геометрик фигуралар: кирпич, шакмакны әйтә белергә өйрәтү. |
| Февраль.тема: “Транспорт” | I | “Кечкенә машина” | Яңа төзү детале – пластина белән танышу, төзү материалларын берсе өстенә берсен куеп төзергә өйрәнүне дәвам итү. |
| | II | “Автобус” | Төзү детальләрен берсе өстенә берсен куеп төзи белү осталыгын үстерү. |
| | III | “Үрнәк буенча автобус һәм йөк машинасы төзү” | Үрнәккә карап,аңлату юлы аша төзергә өйрәнү. |
| | IV | “Поезд” | Зурлык һәм төс төшенчәләрен ныгыту, төзү эзлеклелеген аңлата белергә өйрәтү. |
| Март. Тема: “Язгы чыңлау” | I | “Матрешкалар өчен эскәмия” | Яңа алым – төзү детальләрен тоташтырырга өйрәтү. |
| | II | “Зур һәм кечкенә эскәмия” | Төзү детальләре һәм корылмалары буенча аера белергә өйрәнү. |
| | III | “Капка һәм койма” | Төзи алымнарын аңлатмаган килештә, төзи белергә өйрәтү. |
| | IV | “Төрле төсле корылмалар” | Төсе һәм формасы буенча төрле булган төзү детальләрен (кирпич, шакмак, пластина) кулланып төзергә өйрәнүне дәвам итү. |
| Апрель. Тема: “Безнең булышчылар” | I | “Түбәле өй» | Яңа төзү детале – призма белән эшли белүне ныгыту. |
| | II | “Өй” | Төзү материалларын формасы, төсе, зурлыгы буенча аера һәм атый белергә, тйзү эзлеклелеген аңлата белергә өйрәтү. |
| | III | “Үрнәк буенча өй » | Төп төзү алымнарын (кую, өстенә кую, яткыру, салу, каплау) кулланып эшли |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | белүне, төзү детальләрен чиратлаштыра белүне камилләштерү. |
| | IV | “Тәрәзәле өй” | Ел буе өйрәнгән эш алымнарын, төзи белү осталыкларын ныгыту. |
| май | I | “Алда үткәннәрне кабатлау” | Ел буе өйрәнгән алымнарны кулланып, теләк буенча төрле корылмалар төзеп уйлау. |
| | II | “Зәңгәр шакмак һәм кызыл кирпичтән койма” | Зурлыгы һәм төсе төрле булган детальләрдән койма төзи белү осталыгын үстерү, геометрик фигуралар: кирпич, шакмакны әйтә белергә өйрәтү. |
| | III | “Автобус” | Төзү детальләрен берсе өстенә берсен куеп төзи белү осталыгын үстерү. |
| | IV | “Куянга өй” | Геометрик фигуралар: зур һәм кечкенә шакмаклар, призма белән таныштыруны дәвам итү, төзеп һәм уйнап күрсәткәндә тәрбиячегә булышырга теләк тудыру. |

### 2.3.3. «СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ»белем бирү өлкәсе

***СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ***

***Аңлатма язуы***

**Сөйләм үстерү мохите.** Аралашу чарасы буларак,балаларның сөйләмнәрен үстерүгә булышлык итү. Иптәшләре һәм өлкәннәр белән аралашу мөмкинлеге бирә торган төрле йомышлар кушу (“ Чишенү бүлмәсенә кара але, кем килде микән?” , “Оля апаңнан бел һәм миңа сөйлә”, “ Митяны кисәт.... Митяга син нәрсә диден? Митя нәрсә җавап бирде?”).

Балаларга мөстәкыйль карау,уйнау өчен китаплар, рәсемнәр, уенчыкла, предметлар (3-4 курчаклы матрешка, ачкыч белән борып хәрәкәткә китерә торган уенчыклар, конфет кәгазьләре салынган шкатулка һ.б.) тәкъдим итү.

Бу әйберләр, шулай ук кызыклы хәлләр, вакыйгалар (мәсәлән, йорт хайваннарының хәйләкәрлеге, аларнын яшәү рәвеше һ.б.) турында нәниләргә аңлаешлы, мавыктыргыч итеп сөйләү.

Тәрбияченең сөйләмен игътибар белән тыңларга гадәтләндерү.

**Сүз байлыгын үстерү**

Әйләнә – тирәдә ориентлашуны киңәйтү нигезендә башкалар сөйләмен аңлауларын үстерү, сүзлекләрен үстерү, сүзлекләлен активлаштыру.

Тәрбияченең кушуы буенча, әйберләрнең төсе һәм зурлыгына карап, аларны табып китерергә (“кызыл машинаны алып кил”, Ак шарны тәгәрәт” , “Зур тупны мина бир”, “Кечкенә аюга җыр җырла”) ; урынын билгеләргә ( Кызыл машина югары киштәдә”, “Ак шар өстәл өстендә”, “Кечкенә туп өстәл астында»); кешеләрнең гамәлләрен һәм хайваннарның хәрәкәтләрен күрсәтергә ( аю булып йөреп күрсәт; гөлләргә ничек су сибәбез) өйрәтү.

**Авазларны дөрес әйтергә өйрәнү**

Сузык һәм тартык (сызгырулы, чыжылдаучы һәм сонор авазлардан тыш)авазларны, аваз ияртемнәрен, аерым сүзләрне , 3-4 сүздән торган фразаларны дөрес әйтергә өйрәтү буенча күнегуләр башкару.

Артикуляция һәм тывыш аппаратын, Сулыш (тын) алуны һәм ишетү игътибарлылыгын үстерүгә булышлык итү.

Сөйләмдә тавышның югарылыгын һәм көчен куллана белүне (охшату буенча) формалаштыру “ Песи, прес-сс!”, “Кем килде?” , “ Кем шылтырата?”

**Бәйләнешле сөйләм**

Балаларны өлкәннәрнең сөйләмен аңларга һәм кечкенә дидактик хикәяләрне күрсәтмә материаллардан башка тыңларга өйрәнү . Гади ( “нәрсә бу?” “кем бу?” , “нәрсә эшли?”), тора – бара катлаулырак (“нәрсә кигән?”, “нәрсә алып бара?” , “ кемгә?” , “кайда?”, “кайчан?”) сорауларга җавап кайтара белүләренә итешү.

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | I | “Кем нәрсә эшли?” | 1) балаларның сөйләмен үстерергә ярдәм итү, рәсемнәр карарга, анда сурәтләнгән предметларны һәм аларның сыйфатларын әйтергә, рәсемдә сурәтләнгән уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтү;<br>2) игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | II | «Предметларның төсләрен тану һәм атау”.”Паровоз” дидактик уены. | 1) төсләрне белдерә торган сыйфатлар (кызыл, яшел, сары) хисабына балаларның сөйләмен баету, [ү] ава зының дөрес әйтелешенә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерү;<br>3) эшчәнлеккә карата кызыксыну, бергәләп уйнау, шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| | III | “Уенчыклар бездә кунакта”. | 1) төсне, зурлыкны, эш-гамәлне белдерә торган сүзләр (зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, эчерт, керт) хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру, аралашу осталыгын формалаштыру;<br>2) исеме, төсе, размеры буенча балаларның предметны табу осталыгын, сенсор тою сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) уенчыкларга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | IV | “Пирамидалар”. | 1) балаларны предметларның зурлыгын, төсен билгеләргә өйрәтү, төсне (кызыл, яшел, сары, зәңгәр),зурлыкны (зур — кечкенә, зуррак — кечкенәрәк, иң зурысы — иң кечкенәсе) белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүз байлыгын арттыру, аваз ияртемнә рен ачык әйтүдә күнектерү;<br>2) игътибарны, кабул итүне, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) түземлелек, дидактик уеннар белән кызыксыну тәрбияләү. |
| Октябрь | I | “Яшелчәләр”. | 1) яшелчәләрне белдерә торган исемнәр (бәрәңге, помидор, суган, кишер) һәм аларның үзлекләрен белдерүче сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету, яшелчәләрне танырга өйрәтү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү;<br>2) балаларның сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) яшелчәләр, аларның файдасы турында мәгълүмат бирү. |
| | II | “Җил исә” уен күнегүе | 1) балаларның төсләр турындагы күзаллавын ныгыту, җәнлекләрнең нәрсә ашавы турындагы белемнәрен ачыклау; ялап эчә, кимерә, чүпли, ашый фигыльләрен сөйләмдә активлаштыру, авыз аша һаваны әкрен, салмак кына чыгарырга өйрәтү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2) игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;<br>3) җәнлекләргә, кошларга карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | III | “Урманда”. | 1) балаларның олылар белән аралашу теләген хуплау, исем һәм сыйфатларны кулланырга өйрәтү: йомшак йонлы койрык, озын колаклы куян, юан тәпиле аю, соры бүре; кыргый хайваннарның тышкы билгеләрен һәм гадәтләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне активлаштыру: төлке бара, куян сикерә, аю алпан-тилпән йөри һ.б.;<br>2) ишетү игътибарын, координа цияләрне, ритм хикәясен үстерү;<br>3) кыргый хайваннарга карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | IV | “Алсу бүлмәсе”. | 1) балаларны өй җиһазларын таный һәм атый белергә өйрәтү; өстәл, урындык, караватъ, шкаф, күзгә кебек исемнәр хисабына сүзлекне активлаштыру, сөйләмнең грамма тик төзелешен камилләштерү;<br>2) балаларның уңай эмоцияләрен, кызыксынучанлыгын үстерү;<br>3) бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| Ноябрь | I | “Бу өйдә кем яши?” дидактик уены. | 1) төркемгә йөрүче балаларның исемнәрен истә калдырырга ярдәм итү, фигыльләрне хәзерге һәм киләчәк заманда куллана белергә өйрәтү, сорауны белдерә торган сүзләрне кулланырга күнектерү;<br>2) игътибарны, кабул итү сәләтен, диалогик сөйләмне үстерү;<br>3) бер-береңә карата игътибар лылык тәрбияләү. |
| | II | “Алсу бездә кунакта». | 1) балаларга һөнәрләр (табиб, полиция хезмәткәре) турында мәгълүмат бирү, грамматик яктан җөмләләрне аңларга һәм аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) игътибарны, хәтерне, күзәтүчәнлекне, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) һөнәрләргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | III | “Әминәнең туган көненә килегез”. | 1) [к] һәм [қ] авазларының сүзләрдә һәм сөйләмдә дөрес әйтелешен ныгыту, килеш кушымчаларын дөрес әйтергә өйрәтү, савыт-сабаларны белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне киңәйтү һәм активлаштыру, гомумиләштерүче сүзләр не аңлый һәм куллана белүләренә ирешү, җөмләләр белән җавап бирергә күнектерүне дәвам итү;<br>2) инициативалы сөйләмне, игътибарны, хәтерне үстерү, башкаларга мөрәҗәгать итәргә теләк тудыру;<br>3) үзара аралашуга омтылыш тәрбияләү. |
| | IV | “Минем гаиләм”. | 1) сөйләмдә ягымлы сүзләрне (әти — әтием, әни — әнием, әби — әбием, сеңел — сеңлем) кулланырга өйрәтү, [ә] авазы ның әйтелешен ныгыту, аны ачык, тиешле дәрәҗәдә кычкырып әйтүгә ирешү, тәрбияче сорауларына җавап бирергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү, зурлар һәм иптәшләре белән ирекле аралашуларына ирешү;<br>3) гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләү. |
| Декабрь | I | ”Купшы чыршы”. | 1) сузык һәм тартык авазларны, аваз ияртемнәрен ачык әйтергә, сыйфатларны дөрес кулланырга күнектерү, түбәндә сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтү;<br>2) сорауларга җавап бирү осталыгын, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3) табигатькә соклану хисләре тәрбияләү. |
| | II | “Куян чыршы янында”. | 1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстә, өстендә) кулланырга, кайда? кая? сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү, тавыш көчен дөрес куллану осталыгын формалаштыру;<br>2) игътибарны үстерү, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәүдә күнектерү;<br>3) нәфис сүзгә кызыксыну тәрбияләү. |
| | III | “Юлны чистартабыз”. | 1) балаларның кыш һәм кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнәрен формалаштыру, көрәк белән эшләргә өйрәтү, ишег алдын җыештыручы хезмәте белән таныштыру, балаларның сүзлеген активлаш тыру, аерым сүзтезмәләр не (зур көрәк, кечкенә көрәк, ак кар, күп кар, әз кар) ачык итеп әйтүдә күнектерү;<br>2) хезмәт күнекмәләрен, кеше хәрәкәтләрен ими-тацияләү осталыгын үстерү;<br>3) зурларга ярдәм итү һәм гади хезмәт хәрәкәтләре<br>үтәү теләге тәрбияләү. |
| | IV | “Тылсымлы таякчык”. | 1) балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү, төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту, төсне белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, ишетү осталыгын үстерү;<br>3) бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| Январь | I | “Кошлар” . | 1) балаларны аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтергә, алардан фигыльләр (гөр-гөр — гөрли, чырык-чырык — чыркылдый, кар-кар — каркылдый) ясарга өйрәтү, гомумиләштерүче сүзләрне (тавык, әтәч, каз — йорт кошлары) куллануда күнектерү; кош исемнәрен, гәүдә өлешләрен, хәрәкәтне белдерүче сүзләр хисабына сүз байлыгын активлаштыру, балаларны кошлар белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, сөйләмен үстерү;<br>3) кошларга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | II | “Шундый ук предметны тап” дидактик уены. | 1) үз фикерләрен, грамматик яктан дөрес итеп, ике-өч сүздән торган гади җөмләләр белән белдерергә өйрәтү, гомумиләштерү күнекмәсе булдыру, предметларны чынбарлыкта һәм рәсем дә танырга өйрәтү, предметларның билгеләнешен ачык лау, предмет исемнәрен атау хисабына (сабын, теш щёткасы, теш пастасы, сөлге) һәм сөйләмдә кулланылган фигыльләр ярдәмендә сүзлекне активлаштыру һәм баету;<br>2) тәрбияче сорауларына гади җөмлә белән тулы җавап бирү осталыгына ирешү, игътибарны, сенсор тою сәләтен үстерү;<br>3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| | III | “Кошлар”. | 1) балаларны кайда? кая? сорауларына җавап бирергә, сөйләмдә өстенә, артына, астына сүзләрен кулланырга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) уенга кызыксыну тәрбияләү. |
| | IV | Бармак уены б-н | 1) халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | таныштыру. ”Йорт хайваннары “ уен күнегүе. | катлаулы булмаган фразаларны кулланудa күнектерү, йорт хайван нарының исемнәрен ныгыту; мөгри, кычкыра, мияулый, өрә фигыльләре хисабына балаларның сүзлеген активлаштыру; [м], [у] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) хәтерне, кабул итү сәләтен, авазларны әйтү күнек мәләрен үстерү;<br>3) халык авыз иҗатына, йорт хайваннарына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| Февраль | I | “Машина һәм самолет”. | 1) балаларны уенчыкларның өлешләрен, төсен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтү; исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү, [у] сузык авазын әйтүдә күнектерү; очучы, очып китү, очып төшү, йөк машинасы, самолёт сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру, уенчыклар (машина, самолёт) белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның нинди? кайда? нәрсә ташый? сорауларына гади җөмләләр белән җавап бирү осталыгына ирешү, игътибарын үстерү;<br>3) шофёр, очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләү. |
| | II | «Алсу урамга җыена” | 1) балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтү, төсләр турындагы күзаллауларын ныгыту, төсне белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, ишетү осталыгын үстерү;<br>3) бергәләп шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| | III | “Ашамлыкны дөрес әйт” дидактик уены | 1) халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, катлаулы булмаган фразаларны кулланудa күнектерү, ашамлыкларның исемнәрен ныгыту;<br>2) хәтерне, кабул итү сәләтен, авазларны әйтү күнек мәләрен үстерү; |
| | IV | “Безнең гаилә” | 1)Гаилә әгъзаларының рәсемнән табып дөрес әйтә белүләренә ирешү.<br>2)Диологик сөйләмне үстерү.<br>3)Рәсем карауга кызыксыну уяту. |
| | I | “Чуар тавык” әкиятен уку. | 1) балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итү, әкиятне тыңлау теләге тудыру; чуар, күкәй, алтын, гади, тычкан кебек сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баету;<br>2) тәрбияче башлаган җөмләне дәвам итү осталыгын, хәтерне, игътибарны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) әкият персонажларына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| Март | II | «Кына гөле” | 1) балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, бүлмә гөлләренең өлешләрн өйрәтү, аларның сыйфат билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) гөлләр белән кызыксынуларын үстерү;<br>3) өлкәннәргә гөлләрне карарга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | III | «Бармак уеннары» | 1) халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, катлаулы булмаган фразаларны кулланудa күнектерү, ашамлыкларның исемнәрен ныгыту;<br>2) хәтерне, кабул итү сәләтен, авазларны әйтү күнек мәләрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | үстерү; |
| | IV | «Карга әйтә” эндәшен ятлау | 1) халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, катлаулы булмаган фразаларны кулланууда күнектерү, ашамлыкларның исемнәрен ныгыту;<br>2) хәтерне, кабул итү сәләтен, авазларны әйтү күнек мәләрен үстерү; |
| Апрель | I | “Йөк машинасы”. | 1) машина, аның өлешләре турында балаларның белемнәрен арттыру, ком һәм аның үзлекләре белән таныштыру; машинаның төрен, өлешләрен, комның үзлекләрен белдерә торган исемнәр, сыйфатлар хисабына сүзлекне активлаштыру; [в], [п] авазларының дөрес әйтелүдә күнектерү;<br>2) кызыксынучанлыкны, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) тәрбияче һәм яшьтәшләре белән аралашу теләге тәрбияләү. |
| | II | “Мәрьямне табыйк” | 1)Тәрбиячене кушуы буенча әйберләрнең төсенә, зурлыгына карап табып китерергә өйрәтү.<br>2)Темага кагылган сүзләрне сөйләмдә куллана башлау.<br>3)Балаларда гади хезмәт күнекмәләрен устерү. |
| | III | “Төшке аш” рәсемен карау” | 1) Рәсемнән табып дөрес әйтә белүләренә ирешү.<br>2)Диологик сөйләмне үстерү.<br>3)Рәсем карауга кызыксыну уяту. |
| | IV | “Язгы урманда”. | 1) кайда? нинди? сорауларына җавап бирергә өйрәтү; өстә, агач төбендә сүзләрен куллану хисабына сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; аваз ияртемнәрен ачык, төгәл әйтүдә күнектерү, [ш] авазының әйтелешен ныгыту, ел фасылларына бәйле табигатьтәге үзгәрешләр турындагы белемнәрне формалаштыруны дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләү. |
| | I | “Бүлмә гөлләре” | 1) балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, бүлмә гөлләренең өлешләрен өйрәтү, аларның сыйфат билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) гөлләр белән кызыксынуларын үстерү;<br>3) өлкәннәргә гөлләрне карарга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | II | “Беренче чәчәкләр”картина сын карау | 1) балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, бүлмә гөлләренең өлешләрен өйрәтү, аларның сыйфат билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баету;<br>2) гөлләр белән кызыксынуларын үстерү;<br>3) өлкәннәргә гөлләрне карарга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | III | “Агачлар” | 1) балаларның агачлар турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>2) игътибарны, хәтерне үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге, тыңлаучанлык, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Май | IV | “Балалар бакчасы ишегалдында”. | 1) исемнәр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына сүз байлыгын үстерү; фигыльләрне һәм сыйфатларны исемнәр белән яраклаштыруда күнектерү, балаларны бакча ишегалдында үсә торган үсемлекләр исеме белән таныштыруны дәвам итү, табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында белемнәрне киңәйтү;<br>2) төсләрне, матурлыкны белдерүче сыйфатлар ярдәмендә сөйләм теле компонентларын үстерү;<br>3) табигать объектларына карата кызыксыну, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү. |

### *МАТУР ӘДӘБИЯТ БЕЛӘН ТАНЫШУ*

### *Аңлатма язуы*

«Матур әдәбият уку» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Нәниләрне әкиятләр, халык җырлары, язучыларның әсәрләрен тыңларга өйрәтү. Әсәрләрне укыганда уенчыклар, рәсемнәр (фланелеграф ), өстәл театры персонажларын һәм башка төрле күрсәтмә материаллар куллану. Шулай ук әсәрләрне күрсәтмәлектән башка да тынлый белергә күнектерү.

Таныш шигырьләрне укыганда балаларга шигырь юлларындагы соңгы сүзләрне, фразаларны әйтеп бетерергә мөмкинлек бирү.

Өлкәннәргә ияреп шигырь юлларын тулысы белән кабатлау теләкләрен хуплау. 2яшь 6 айлык балалар белән яхшы таныш әкиятләрне уйнау.

Китаптагы рәсемнәрне карау теләге уяту, рәсемдәге таныш әйберләрне күрсәтеп, нәрсә икәнлекләрен әйттерү: “ Бу кем (нәрсә)?” , “Нәрсә эшли?” кебек сораулар бирергә өйрәтү. Катлаулы булмаган сюжетлар рәсемнәрнен эчтлеген сөйләү. Персонажларның эш – гамәлләрен уйнап күрсәтергә тәкъдим итү (« Чебиләр ничек җим чүплиләр?”, “ Куян ничек сикерә?”, “Песи ничек ашый?” һ.б.).

Китапны үзе алып, рәсемнарен карап утыручы балага игътибар итү, аны мактау.

### *Комплекслы – тематик план*

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| Сентябрь | 1 | “Үчтеки-үчтеки!- такмагын уку. | 1) балаларны фольклор әсәрләре белән кызыксындыру, шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) нәфис сүзгә мәхәббәт тәрбияләү. |
| | 2 | Ә.Бикчәтәева “Туп-туп-тубыбыз” шигырен уку. | 1) балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, таныш предметларны таный һәм атый белергә, шигырьнең авыр әйтелешле аерым сүзләрен дөрес әйтергә өйрәтү, төсләрне аеру күнекмәсен ныгыту;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, хәтерен, уңай эмоция ләрен үстерү;<br>3) уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | 3 | С.Сөләйманова “Ике” шигырен уку. | 1) балаларны шигъри әсәр белән кызыксындыру, аның эчтәлеген аңларга өйрәтү, баланың үзе турында күзаллавын формалашты ру ны дәвам итү; кул, аяк, колак, күз сүзләре хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| | 4 | Хайваннарны чакыру эндәшен уку. | 1) эндәшнең эчтәлеген аңлату; текстның эчтәлегеннән чыгып, аваз иямтемнәрен, ымлыкларны дөрес әйтүләренә, тәрбияченең сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) хайваннарны ярату хисе тәрбияләү. |
| Октябрь | 1 | Д.Гарифуллинның “Йә алар кемнәр” шигырен уку. | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтүне дәвам итү; бак-бак, мә-мә, кар-кар аваз иямтемнәрен кабатлау; балаларны шигырьдә бирелгән диалогка җәлеп итү, сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) кошларга, хайваннарга карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| | 2 | Б.Рәхмәт “Су” шигырен уку. | 1) текстка туры китереп, хәрәкәтләр ясарга өйрә тү, [йу] аваз кушылмасын ачык итеп әйтергә күнектерү; сүз байлыгын үстерү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |
| | 3 | Г.Тукайның “Гали белән кәҗә” шигырен уку. | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, балаларда «Мин — дөньяның бер кешесе» дигән күзаллау булдыру; кәҗә, чирәм, сакал сүзләре хисабына сүзлек байлыгын киңәйтү, хәрәкәтләр өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) балаларда бер-берсенә һәм хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | 4 | З.Туфайлова “Ул зур үскән” шигырен уку. | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү һәм хезмәтнең нәтиҗәсен күрә белергә өйрәтү; утырткан, сипкән, үскән кебек эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру, диалогик сөйләм күнекмәсе формалаштыру;<br>2) балаларның эмоциональлеген үстерү;<br>3) гөлләргә карата сакчыл караш, матурлыкка соклану тәрбияләү. |
| Ноябрь | 1 | “Песи-нечкәбил” бишек җырын җырлау. | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, бишек җыры текстына туры китереп, хәрәкәтләр өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) фольклор әсәрләренә мәхәббәт тәрбияләү. |
| | 2 | М.Җәлилнең “Әтәч” шигырен уку. | 1) күрсәтмәлелек кулланмыйча, әдәби әсәрне тыңлау һәм кабул итү күнекмәләре формалаштыру,йорт кошларын тавышлары буенча танырга һәм исем нәрен атарга өйрәтү, [к] һәм [к] авазларының әйтелешен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү һәм тыңлау сәләтен үстерү;<br>3) йорт кошларына карата шәф катьлелек тәрбияләү. |
| | 3 | Җ.Тәрҗемановның “Маэмай”шигырен уку. | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, аерым сүзләрне һәм зур булмаган фразаларны истә калдырырга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) эткә карата миһербанлылык тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4 | Ә.Бикчәнтәева ның«Беренче адым» шигырен уку. | 1) балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, авыр әйтелешле кайбер сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) сорауларга җавап бирү күнекмәсен үстерү;<br>3) күмәк эшчәнлек күнекмәсе тәрбияләү. |
| Декабрь | 1 | “Карга әйтә” эндәшен уку. | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, балаларның кошлар турында белемнәрен арттыру һәм ныгыту, кошларның тышкы кыяфәтенә игътибар итү, сүз байлыгын арттыру, [к] авазының дөрес әйтелешенә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) кошлар белән кызыксыну теләге уяту. |
| | 2 | Ә.Ерикәйнең “Беренче кар” шигырен уку. | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, әсәр аша табигать дөньясына җәлеп итү, кышкы табигать турында мәгълүмат бирү; йомшак, ап-ак сыйфатлары хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;<br>2) балаларның катлаулы сорауларга җавап бирү осталыгын, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) табигатькә карата мәхәббәт уяту. |
| | 3 | Җ.Тәрҗеманов ның “Йокы бабай” әкиятен сөйләү. | 1) әкиятнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) сорауларга дөрес җавап бирү омтылышы уяту. |
| | 4 | С.Летованың “Кар бабай” хикәясен уку. | 1) күләме буенча зур булмаган әдәби әсәрне (хикәяне) күрсәтмәлелек кулланмыйча тыңлау һәм кабул итү, сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү, балаларның әңгәмә вакытында җиңел һәм иркен аралашуларына ирешү, сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның игътибарын, бергә ләп тыңлау күнекмәсен үстерү;<br>3) сүз сәнгате белән кызыксыну тәрбияләү. |
| | 5 | Ш.Маннур «Яратам» шигырен уку | 1) күләме буенча зур булмаган әдәби әсәрне күрсәтмәлелек кулланмыйча тыңлау һәм кабул итү, сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү, балаларның әңгәмә вакытында җиңел һәм иркен аралашуларына ирешү, сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның игътибарын, бергә ләп тыңлау күнекмәсен үстерү;<br>3) сүз сәнгате белән кызыксыну тәрбияләү. |
| | 1 | Ә.Каринең “Тавык” шигырен уку. | 1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү, фланелеграфта шигырь эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр яки уенчыклар күрсәтү; кайбер фразаларны кабатлатып, балаларның сөйләмен активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әбиләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү. |
| Январь | 2 | “Хайваннарны чакыру” эндәшен уку.(Кабатлау). | 1) эндәшнең эчтәлеген аңлату; текстның эчтәлегеннән чыгып, аваз ияртемнәрен, ымлыкларны дөрес әйтүләренә, тәрбиячене сорауларына дөрес җавап бирүләренә ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү;<br>3) хайваннарны ярату хисе тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3 | Г.Таһировның “Йокла курчак” шигырен уку. | 1) шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү; [ә], [ү] авазларын дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) курчакка карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | 4 | Т.Н. Гайсин “Гөлсөя” уку. | 1) балаларны «Гөлсөя» әсәре белән таныштыру, әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, сорауларга җавап бирү осталыгына өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, активлыгын үстерү;<br>3) әсәр белән кызыксындыру. |
| Февраль | 1 | “Шалкан” рус халык әкиятен уку. | 1) балаларны яңа әсәр белән таныштыру, әкиятне аңлап тыңларга өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) халык иҗатына карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | 2 | Ш.Маннур “Яратам” шигырен уку. | 1) шигырьнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү, [ә] авазын дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) әти-әниләргә, туганнарга мәхәббәт тәрбияләү. |
| | 3 | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерү. | 1) әкият белән таныштыруны дәвам итү; балаларны сәхнәләштерү эшчәнлегенә җәлеп итү, уен ба рышында фразаларны дөрес әйтү осталыгына ирешү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, активлыгын үстерү;<br>3) әкиятләр белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү. |
| | 4 | Э.Шарифуллина “Иң матур әни” шигырен уку. | 1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итү; кайбер фразаларны кабатлатып, балаларның сөйләмен активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) әниләргә карата ихтирам, ярату хисләре тәрбияләү.<br>аңлау, сөйләп карау. |
| | 1 | “Бармак”уены. | 1) уен уйнарга өйрәтүне дәвам итү; [а], [у], [ә] сузык авазларын дөрес әйтергә күнектерү,<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) әкият геройлары белән кызыксыну тәрбияләү. |
| | 2 | “Тук - тук, тукран ..“ эндәшен уку. | 1) шигъри текстны тыңлау осталыгы формалаштыру, кошлар белән таныштыруны дәвам итү, аваз ияртемнәрен кабатлау, [т], [к] һәм [к] авазлары кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2) балаларның игътибарын үстерү;<br>3) кошларга карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| | 3 | “Кәккүк-чыпчык”-уены. | 1. [ч ] ,[ к] һәм [к ] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү, сүзлекне активлаштыру;<br>2. балаларның эмоциональлеген үстерү.<br>3. фольклор әсәрләре белән кызыксыну тәрбияләүне дәвам итү. |
| | 4 | “Йомры икмәк” әкиятен уку | 1) балаларны әкият белән кызыксындыру, аның эчтәлеген аңларга өйрәтү, баланың үзе турында күзаллавын формалашты ру ны дәвам итү; кул, аяк, колак, күз сүзләре хисабына сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итү сәләтен үстерү;<br>3) гигиена күнекмәләре тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Апрель | 1 | Ш.Галиевның “Яз” шигырен уку. | 1) балаларның шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешү, язгы табигать турында мәгълүмат бирү; [т] авазын, тып аваз ияртемен дөрес әйтергә күнектерү, сүз байлыгын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерү;<br>3) язгы табигать күренешләре белән соклану хисе тәрбияләү. |
| | 2 | З.Туфайлованың “Ул зур үскән”шигырен уку. | 1) шигъри әсәрне аңлап кабул итү ләренә ирешү, бармак театры эле ментларын өйрәтүне дәвам итү, сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның кабул итү һәм истә калдыру сәләтен үстерү;<br>3) бер-берсенә карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| | 3 | “Тор-тор, тургай” такмагын уку. | 1) такмакның эчтәлеге белән таныштыру, [т] авазын дөрес әйтергә күнектерү, аваз иялтемнәре хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен үстерү;<br>3) фольклор әсәрләре белән кызыксындыруны дәвам итү. |
| | 4 | “Кояш чык-чык-чык” эндәшен уку. | 1) балаларга эндәшнең эчтәлеген аңларга, сюжетны истә калдырырга ярдәм итү;<br>2) балаларның тыңлый белү осталыгын, уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) күмәк эшчәнлек белән кызыксындыру. |
| Май | 1 | Ә.Кәринең “Чебиләр” шигырен уку. | 1) күрсәтмәлелек кулланмыйча, шигъри әсәрне тыңларга өйрәтү, [ч] авазын дөрес әйтергә күнектерү;<br>2) балаларның уңай эмоцияләрен үстерү;<br>3) йорт кошларына карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | 2 | Ф.Кәримнең “Күбәләк” шигырен уку. | 1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтү, гади сорауларга җавап бирү теләге уяту, аваз иялтемнәрен өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын,хәтерен, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү;<br>3) йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| | 3 | С. Сөләймановаӊың «Кызыл әтәч» шигырен уку | 1) шигъри әсәрне тыңларга өйрәтү, гади сорауларга җавап бирү теләге уяту, аваз иялтемнәрен өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү;<br>3) йорт кошларына карата шәфкатьлелек тәрбияләү. |
| | 4 | Д. Гарифуллинның «Мыраубикә» шигырен уку. | 1) шигырь ярдәмендә песи белән таныштыруны дәвам итү, песи турында мәгълүматларны ныгыту һәм киңәйтү; мыр-мыр, гыр-гыр аваз иялтемнәрен өйрәтү;<br>2) сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) песиләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | 5 | Р.Файзуллинның ”Рәсем ясыйм” шигырен уку. | 1) шигырь белән таныштыруны дәвам итү$<br>2) сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) рәсем ясаучыларга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |

### 2.3.4. «СӘНГАТИ - ЭСТЕТИК ҮСЕШ»белем бирү өлкәсе

***Җыр***

***Аңлатма язуы***

«Музыка» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә Һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар музыкасына карата кызыксыну уяту, аны тыңларга теләк белдерү. Аның хисле-образлы эчтәлеге турында сөйләү, кичерешләр белән бүлешү.

Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлап, музыканың төп өч жанры: «җыр», «бию», «марш» төшенчәләрен бирү. Балаларның музыка характерын, кәефен бирә белү сәләтләрен үстерү.

Музыка уен кораллары (курай, кубыз, тальян гармун һ. б.) һәм аларның яңгырашы белән танышуны дәвам итү. Татар җырларын дөрес, сәнгатьле итеп һәм аңлап башкарырга, сүзләрен ачык итеп әйтергә күнектерү.

Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «чүгү», «аяк очларында күтәрелү», «берле бишек», «баш-үкчә», «култыклашып әйләнү», «борма» (гади вариант) һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү.

Музыка характерына туры китереп, ритмлы хәрәкәтләр башкаруны формалаштыру.

Хәрәкәтле импровизацияләрдә музыкаль образны чагылдырырга омтылуны хуплау, балалар белән бергә гәүдәләнеш вариантларын («тәкәббер» әтәч, «кайгыртучан» тавыклар, тик-тормас чебиләр һ. б.) тикшерү, музыкаль әкият эчтәлеге һәм характерына дөресрәк туры килә торган образны сайларга булышу, һәр иҗади табышны хуплау.

Балалар эшчәнлегенең төрле структурасына музыка өстәү; матур әдәбият, сынлы һәм театр сәнгатьләре әсәрләрен файдаланып, кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә ярдәм итәрлек музыка астында катнаш музыкаль эшчәнлек үткәрү.

### 2.3.5. «ФИЗИК ҮСЕШ»белем бирү өлкәсе

***Сәламәтлек***

***Аңлатма язуы***

«Сәламәтлек» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту буенча эшне; оешма төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш үзенчәлекләрен, шулай ук төбәктәге климатик һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру эшен дәвам итү.

Шәхси гигиена процесслары турындагы күзаллауларын баету. Гигиена нормалары һәм кагыйдәләрен аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә үтәүләренә ирешү.

Гади һәм чиста киенү, киемнәрне тәртипләп төрү, бүлмәдә чиста аяк киемендә йөрү күнекмәләрен үстерү.

Ашаганчы һәм ашагач, пычрангач, туалеттан соң кулларын мөстәкыйль рәвештә юарга, гадәтләндерү.

Пөхтә ашау күнекмәләрен камилләштерү: ризыкны азлап кына алу, тавышсыз гына ашау, бик кайнар ризык ашамау, коймау, савыт-сабаны дөрес файдалану.

Милли ризыклар һәм эчемлекләр (умач, татарча азу, казам пылавы, кара җимеш һәм өрекле чәй, хуш исле чәй һ. б.) белән таныштыру.

Бала организмы өчен кирәк булган витаминнар турында күзаллау булдыру. Ризык кабул итү режимын үтәү, җиләк- җимеш, яшелчә, балык һәм сөт ризыкларын (кайнаган сөт, кефир, корт), ит һәм башка файдалы ашамлыкларны куллануга ихтыяҗ тәрбияләү.

«Сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре, халык медицинасының кайбер чаралары белән таныштыру. Бәрелгәндә, киселгәндә үз-үзеңә һәм башка балаларга элементар ярдәм күрсәтү, үз сәламәтлегең турында кайгырту күнекмәләре формалаштыру.

## *ХӘРӘКӘТНЕ ҮСТЕРҮ.*

### *Аңлатма язуы.*

«Физик культура» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда физик культурага кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.Балаларда хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ формалаштыру. Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү. Кагыйдәләрне мөстәкыйль рәвештә үтәргә өйрәтү.Хәрәкәтләнү тәҗрибәсен баету.Хәрәкәтле уеннарда балаларның иҗади сәләтләрен (уен вариантлары, катнаш хәрәкәтләр уйлап чыгару) үстерү.

### *САФҺАВАДА ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР.*

Хәрәкәтле уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлекләрен ныгыта, хәрәкәт координациясен яхшырта. Әлеге уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш гамәлләр, хәрәкәтләрен барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен бапрышанда балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләрен үзләштерәләр.

### Комплекслы-тематик план

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | “Туп,туп, тубыбыз” | Биеклеккә сикерә белү күнекмәләрен үстерү. |
| | II | «Тупны куып тот» | Бер юнәлештә йөгерергә өйрәтү, балаларның хәрәкәт активлыгын үстерү. |
| | | “Тигез юл буйлап” | Аякларны югары күтәреп атлап йөрергә өйрәтү һәм алга таба хәрәкәтләнеп ике аякта сикерә белү күнекмәләрен үстерү. |
| | III | “Тигез юл буйлап” | Йөгерү тизлеген, сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясый белү осталыгын үстерү. |
| | IV | «Кайда шалтырый» | Пространствода ориентлашырга өйрәтү, ишетеп кабул итә белү сәләтен үстерү. |
| | | “Чыпчыклар” | Таралып йөгерә белү күнекмәләрен үстерү, дус –тату уйнауны булдыру. |
| Октябрь | I | “Уенчыкны эзләп тап” | Игътибарлылык, пространствода ориентлаша белү күнекмәсен үстерү. |
| | | “Төсле автомобильләр” | Төсләр белән танышуны дәвам итү, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәнү. |
| | II | “Кайда шалтырый” | Простррнствода ориентлашырга өйрәтү, ишетеп кабул итә белү сәләтен үстерү. |
| | | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан ике аякта ераклыкка сикерергә өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | “Куяннар” | Сикерү күнекмәләрен, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| | | “Чыпчыклар һәм автомобиль” | Юл йөрү кагыйдәләре турында сөйләшү, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү, игътибарлылык тәрбияләү. |
| | IV | “Кояш һәм яңгыр” | Игъбарлылык тәрбияләү, балаларның физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Мине куып тотыгыз” | Йөгереклелек һәм җитезлек тәрбияләү. |
| ноябрь | I | “Кошлар очалар” | Игътибарлылык, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | “Төз ыргыт” | Тупны ыргытырга һәм тотып алырга өйрәтүне дәвам итү, кул чуклары эшчәнлеген үстерү. |
| | II | “Инеш аша” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, ике аякта ераклыкка сикерә белү күнекмәсен үстерү. |
| | | “Үз төсеңне тап” | Хәтерне, җитезлекне үстерү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга өйрәтүне дәвам итү, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | III | “Көн-төн” | Коллективта бергә уйнау теләге уяту, пространствода ориентлаша белергә, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәтү, ишетү сәләтен үстерү. |
| | | «Чыпчыклар һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | IV | “Куянкай” | Балаларны бер-берсе белән аңлашып кирәк чакта ярдәм итеп уйнарга өйрәтүне дәвам итү, хәрәкәт активлыгын үстерү. |
| | | “Мине куып тотыгыз” | Пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| декабрь | I | “Песи һәм кошчыклар” | Хәрәкәт координациясен, җитезлекне үстерү, уенга кызыксындыру тәрбияләү. |
| | | “Кайда шалтыраттылар” | Ишетү сәләтен үстерү,реакцияләренең тизлеген көчәйтү. |
| | II | “Кем беренче?” | Йөгерү тизлеген үстерү, максатка ирешүчәнлек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү. |
| | | “Кошлар очалар” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбиял. |
| | III | “Уенчыкны алып кил” | Җитезлек тәрбияләү, хәрәкәт активлыгын үстерү, пространствода ориентлаша белү күнекм. үстерү. |
| | | “Капкага керт” | Төз ыргыта белү күнекмәсен үстерү, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | IV | “Мине куып җит” | Җитезлекләрен, бер – бер артлы йөгерә белү күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Сукмак буйлап” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләре бирү. |
| январь | I | “Күрсәт әле,үскәнем!” | Хәрәкәтләрне дөрес кабатлау, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Куянкай” | Ике аякта сикерү күнекмәләрен үстерү, җитезлек тәрбияләүне дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II | “Кошлар очалар” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, бер - бер артлы йөгерү күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Төсле машиналар!” | Күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | III | “Минем янга килегез” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итә белү күнекмәләре тәрбияләү. |
| | | “Әтәч һәм тавыклар” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыру. |
| | IV | “Бау аша сикер” | Ике аякта биеклеккә сикерә белү күнекмәсен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыка туктагач түгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек тәрбияләү. |
| февраль | I | “Йонлач көчек” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлаша белү күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү. |
| | | “Төз ыргыт” | Төз ыргыта белү күнекмәсен үстерү, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | II | “Төлке һәм куяннар” | Сигнал буенча хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү, сизгерлекләрен үстерү. |
| | | “Кыш бабай” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләре тәрбияләү. |
| | III | “Куышлы” | Җитезлекне, тизлекне булдыруны дәвам итү, дус – тату уйнау теләкләре тудыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |
| | IV | “Кошлар очалар” | Хәрәкәт тизлеген үстерүне дәвам итү, төрле юнәлештә очу күнегүләрен башкарып йөгерергә, сигналларга игътибар итәргә өйрәтү. |
| | | “Соры куян юына” | Культура гигиена күнекмәләрен тәрбияләү, булышу, үз-үзенә хезмәт күрсәтә белү күнекмәсен үстерү, уйлап эш итәргә өйрәтү. |
| март | I | “Таяк аркылы атла?” | Тизлек, сизгерлек үстерү, дус –тату уйнауны булдыруны дәвам итү, күрсәтелгән хәрәкәтләрне төгәл итеп башкарырга өйрәтүне дәвам итү. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач түгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек үстерү. |
| | II | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан ике аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү. |
| | | “Төз ыргыт” | Тупны тотарга, туптан качарга өйрәтүне дәвам итү, төз атуны булдыру, балаларның хәрәкәтчәнлекләрен, җитезлекләрен үстерү. |
| | III | “Флагка кадәр сикер” | Сикерү күнекмәләрен үстерү,, бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | | «Төсләр сату » | Йөгерү тизлеген үстерү, пространствода ориентлашу күнекмәләрен, төсләр турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| | | “Күрсәт әле, үскәнем!” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| Апрель | I | “Төлке һәм куяннар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | | “Тупны тәгәрәт” | Тупны предметлар аша тәгәрәтү, максатка ирешүчәнлек, башлаган эшне азагына кадәр эшләп чыгу күнекмәләрен үстерү. |
| | II | “Кояш чык, болыт кач!” | Сигнал буенча хәрәкәт итәргә, пространствода ориентлашырга өйрәтү, җитезлек тәрбияләү. |
| | | “Флагка кадәр йөгер” | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Кошлар очып килделәр” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү өстендә эшне дәвам итү. |
| | | “Әбәк” | Пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | IV | “Черки” | Йөгерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү, пространствода ориентлашуны камилләштерү. |
| | | “Куяннар” | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| Май | I | “Сукмак буйлап” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Тупны тәгәрәт” | Тупны белән уйный белү күнекмәләрен үстерү . |
| | II | «Поезд” | Игътибар тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | | “Сызыкка басма” | Күзәтүчәнлекләрен, игътибарлыкларын үстерү, этешми-төртешми уйнау күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Кояш һәм яңгыр” | Сигнал буенча хәрәкәт итәргә ,уен кагыйдәсен бозмый уйнарга өйрәтү. |
| | | “Очкычлар” | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| | IV | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач түгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |

## *2.4. АТА – АНАЛАР БЕЛӘН ЭШ*

| Ай | Тема |
|---|---|
| Сентябрь | 1.Консультацияләр : “Һәр балада талант бар”, “Балага спорт төре сайлыйбыз”, “Гаилә конфликты һәм балалар”, “Кичке уеннар”, “Кичкә әкият укуның файдасы”.<br>2. Газета “Балалар бакчасына рәхим итегез”<br>4. Ата – аналар җыелышы:<br>-«Юлларда куркынычсызлык»<br>- «Балаларда яхшы сыйфатлар тәрбияләү»<br>- «УМК».<br>5. Табип киңәшләре: “Ваксинопрофилактика”, “Компьютерның һәм телевизорның зыяны”, “Күзләр өчен гимнастика”<br>6. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| Октябрь | 1.Консультацияләр : “Хәрәкәтле уеннарның бала организмы өчен файдасы”, “Бишек җырлары җырлыйбыз”, “Яссытабанлылыкны кисәтү”, “Ни өчен бала уенчыкларны җыярга теләми?”, “Сәләтле бала”.<br>2. Газета “Сәламәт булыгыз!”, “Тәрбияче апа – бәйрәмең белән!”, “Өлкәннәрне тәбриклибез һәм бәйрәм белән котлыйбыз!”<br>3. Өлкәннәрне бәйрәм белән котлау, балаларның үз куллары белән ясаган бүләкләрен бирү.<br>4. Табип киңәшләре: “Бабасыр”, “Баланың гаиләдәге физик тәрбиясе”<br>6. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| Ноябрь | 1.Консультацияләр :“Профилактик прививкалар”, “Музыкотерапия”, “Чиратта торганда һәм транспортта барганда балалар белән уеннар”.<br>2. Газета “Бәйрәм белән, кадерле әниләр!”<br>3. “Әниләр” бәйрәме турында әңгәмә уздыру<br>4. Табип киңәшләре: “Салкын һава турында 5 төрле әти – әниләрнең күзаллаулары”, “Матур һәм сәламәт тешләр”, “Төркемгә чир керсә...”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>6. Белешмәлек “Бала белән бергә уйныйбыз” |
| Декабрь | 1. Консультацияләр : “Саф һавада йөрүнең файдасы”, “Әти –әни булу рәхәт ул”, “Сюжетлы-рольле уеннар аша балаларда туган телне үстерү”, “Өйгә уйный-уйный кайтабыз”.<br>2. Балалар өчен шугалак (тау) төзү.<br>3. Газета “Тәҗрибәләр үткәрәбез”, “Хуш киләсең, Яңа ел”<br>4. “Хуш киләсең, Яңа ел!” бәйрәме уздыру<br>5. Табип киңәшләре: “Салкын тиюдән саклану чаралары”, “Гәүдә төзелеше бозылуы”, “Саф һавада хәрәкәтле уеннар”<br>6. “Сюжетлы-рольле уеннар” күргәзмәсенә әзерлек һәм үткәрү.<br>7. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>8. Ата – аналар җыелышы: “Тәртип кагыйдәләре” |
| Январь | 1.Консультацияләр : “Бармак уеннары”, “Юл һәм балалар”<br>2. Газета “Балаларның юл травматизмы сәбәпләре”, “Чыныктыру чаралары”.<br>3. Ачык ишекләр көне: мастер – класс “Йокыдан уяну гимнастикасы”, “Саф һавада уеннар”<br>4. Мастер –класс “Сәламәт булыйк: чыныктыру алымнары”<br>5. Рәсем конкурсы “Айболит киңәшләре”<br>6. Табип киңәшләре: “Грippка каршы аромотерапия”, “Туберкулездан саклану”, “Яссытабанлылык булса, нишләргә?”<br>7. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| Февраль | 1. Консультацияләр: “Ишетергә һәм тыңларга өйрәнәбез”. “Биибез дә, |

| | |
|---|---|
| | жырлыйбыз”<br>2. Газета “Изге Вәли көне”, “Бәйрәм белән әтием, абыем, бабам”, “Халык ризыклары”<br>3. “Ватанны саклаучылар көне” бәйрәмен уздыру<br>4. Табип киңәшләре:“Отморожение», “Бала йокысы”, “Йокыдан уяну гимнастикасы”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| Март | 1.Консультацияләр: “Тиктормас балаларга уеннар”, “Начар сүзлелек”, “Балаларның урамда уйнау җирлекләре”.<br>2. Рәсем конкурсы “Минем яраткан әкият героем”<br>3. “8март – халыкара хатын кызлар көне” бәйрәме уздыру<br>4. Табип киңәшләре: “Җил чәчәге авыруы”, “Авитаминоз”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| Апрель | 1. Консультацияләр:«Витаминотерапия”, “Балалар алдыйлар”, “Беренче китаплар”.<br>2. Газета “Көлке көне”, “Космонавтика көне”, “Бөек татар шагыйре Г.Тукай”<br>3. Табип киңәшләре: “Тычканнар таратучы чирләр”, “Саф һавада йөрү бик файдалы”<br>4. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
| Май | 1.Консультацияләр: “Кояш, су һәм һава безнең дуслар”, “Музыкаль аптека”, “Балаларның җәйге ялы”, “Су белән уеннар”.<br>2. Газета “Без сезне мәңге онытмабыз!”<br>3. Рәсем конкурсы “Җиңү көне белән!”<br>4. Табип киңәшләре: “Талпан авыруы”, “Баланың күзләрен саклыйк”<br>5. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү.<br>6. Ата – аналар җыелышы: “Оптимистлар илендә” |

## 3. Оештыру бүлеге.
### 3.1. Көндәлек режим

Балалар бакчасында белем бирү эшчәнлеге атнага биш көн тәртибендә үткәрелә. Балалар бакчасында булу вакыты: $6^{00}$ сәгатьтән $18^{00}$ сәгатькә кадәр.

Укыту эшчәнлеге 1 нче сентябрьдән 31 нче майга кадәр. Җәйге сәламәтләндерү вакыты: 1 нче июньнән 31 нче августка кадәр.

Көн тәртибе балаларның яшь үзенчәлекләреннән чыгып төзелә һәм гармонияле үсешенә булыша. Көн тәртибен төзегәндә һәм оештырганда мөһим кабатланучы компонентлар искә алынды:

- ашау вакыты;
- көндезге йокы;
- саф һавада,бинада булу дәвамлыгы.

Төркемдә **көндәлек режим** балаларның яшь үзенчәлекләре һәм СанПин таләпләренә туры китереп төзелгән.

| **Вакыты** | **Эшчәнлек** |
|---|---|
| 6.00-7.55 | Балаларны кабул итү. Мөстәкыйль һәм бердәм уен эшчәнлеге. |
| 7.55-8.00 | Иртәнге гимнастика. |
| 8.00-8.10 | Иртәнге ашка әзерлек. Бердәм эшчәнлек. |
| 8.10-8.30 | Иртәнге аш. |
| 8.30-9.00 | Мөстәкыйль уен эшчәнлеге. ББЭнә әзерлек. |
| 9.00-9.30 | Белем бирү эшчәнлеге. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | дүшәмбе | сишәмбе | чәршәмбе | пәнҗешәмбе | җомга |
| | 1.I. 9.00-9.10<br>II. 9.20-9.30<br>2.I.15.30-15.40<br>II.15.50-16.00 | 1.I.9.00-9.10<br>II.9.20-9.30<br>2.I.15.30-15.40<br>II.15.50-16.00 | 1.I.9.00-9.10<br>II.9.20-9.30<br>2.I.15.30-15.40<br>II.15.50-16.00 | 1.8.50-9.00<br>2.I.15.30-15.40<br>II.15.50-16.00 | 1.8.50-9.00<br>2.I.15.30-15.40<br>II.15.50-16.00 |
| 9.30-9.40 | Икенче иртәнге аш | | | | |
| | 9.35 | 9.35 | 9.35 | 9.35 | 9.35 |
| 9.40-9.50 | Урамга чыгарга әзерлек | | | | |
| 9.50-11.10 | Саф һавада булу. | | | | |
| | дүшәмбе | сишәмбе | чәршәмбе | пәнҗешәмбе | җомга |
| | 9.50-11.10 | 9.50-11.10 | 9.50-11.10 | 9.50-11.10 | 9.50-11.10 |
| 11.10-11.20 | Урамнан керү. Балалар һәм өлкәннәрнең бердәм эшчәнлеге | | | | |
| 11.20-11.30 | Көндезге ашка әзерлек. Бердәм эшчәнлек. | | | | |
| 11.30-12.00 | Көндезге аш. | | | | |
| 12.00-15.00 | Йокыга әзерлек. Көндезге йокы. | | | | |
| 15.00-15.10 | Йокыдан уяту. Йокыдан соңгы гимнастика, чыныктыру процедуралары. | | | | |
| 15.10-15.30 | Кече ашка әзерлек. Кече аш. ББЭнә әзерлек. | | | | |
| 15.30-16.00 | Белем бирү эшчәнлеге. | | | | |
| 16.00-16.10 | Мөстәкыйль уен, балалар һәм өлкәннәрнең бердәм эшчәнлеге. | | | | |
| 16.10-16.20 | Кичке ашка әзерлек. Бердәм эшчәнлек. | | | | |
| 16.20-16.40 | Кичке аш. | | | | |
| 16.40-16.50 | Кичке саф һавага чыгарга әзерлек, урамга чыгу. | | | | |
| 16.50-18.00 | Саф һавада булу. Балалар һәм өлкәннәрнең бердәм эшчәнлеге.<br>Ата-аналар белән әңгәмә. | | | | |

## *3.2.* Методик программа белән тәэмин ителеш

***Әдәбият***

**Төп программалар:**

1. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы «Туганнан алып мәктәпкәчә», Веракса Н.Е., Комарова Т.С., Васильева М.А. редакциясендә
2. 49 нчы "Гөлназ" балалар бакчасының төп белем бирү программасы.

**Парциаль программа:**

«Сөенеч – Радость познания» төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы

**Кулланыла торган әдәбият:**


1. Закирова К.В. «Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе» методик кулланма/К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Г.М.Сафиуллина – Казан:Беренче полиграфия компаниясе,2013.

2. «Үстерешле уеннар» методик кулланма /З.М.Зарипова , Р.С.Исаева.-Казан:Беренче полиграфия компаниясе,2013.-128 б

3.«Әхлак нигезе-матур гадәт» (Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү):Методик кулланма/К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова.-Казан:Мәгариф,2004.-383б.

4. «Иң матур сүз».Уку китабы."Мәгариф"нәшрияты,2000

5. «Игровые занятия с детьми 1-2года»Д.Н.Колдина

6. Балалар бакчасы. Әти-әниләр һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен уку китабы."Раннур"нәшрияты,2003

7. «Туган телдә сөйләшәбез» Күрсәтмә һәм таратма материаллар., 2 -3 яшь.

## 3.3.Предметлы тирәлек мохитен үстерү

Төркемдә белем һәм тәрбия бирү өчен уенчыклар һәм уен почмаклары бар.

1. ***«Туган ягым - Татарстан» почмагы***

- Милли киемдәге курчаклар: татар малае һәм кызы, рус малае һәм кызы
- Габдулла тукай портреты
- Уеннар өчен битлекләр
- Төсле флажоклар
- Аудиоязмалар

***Дидактик уеннар***

- “Төсле флаглар”
- “Пирамидалар”
- “Төсле мозаика”
- “Парын тап”
- “Эчтәлекле рәсемнәр”
- “Төс,форманы, өлеш кисәкләрне аеруга дидактик уен”
- “Нәрсә артык”
- “Бөтеннең өлешләре”
- “Бу нинди төс?”
- “Төс,форма”
- Пазллар
- Шнуровкалар

***Методик әсбаплар һәм аудио кушымта***

- Д.В.Хухлаева. Методика физического воспитания в ДУ.(М.1984)
- Программа воспитания и обучения в детском саду от рождения до школы 2011г.
- А.Н.Фролова Игры-занятия с малышами (Киев1987)

З.В.Лиштван Конструирование (1981).

- З.М. Зарипова, Р.С. Исаева “Үстерешле уеннар”
- З.М.Зарипова, А.Х.Габдрахимова, А.Т.Миникаева “Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге”
- К.В. Закирова, Л.Р. Мортазина “Әй уйныйбыз, уйныйбыз”
- Татар телендә мультфильмнар(4 )
- Туган телдә сөйләшәбез.Методик кулланма өчен аудио-кушымта
- Диск “Балалар бакчасында әдәп- әхлак тәрбиясе”Методик әсбап өчен аудио-кушымта
- Аудио – китап “Татар әкиятләре”
- Диск “Шома бас”
- Диск “Луиза Батыр – Булгари. Сертотмас үрдәк. Бардым күлгә, салдым кармак”
- Диск “Луиза Батыр – Булгари. Африка хикмәтләре”
- Диск “Луиза Батыр – Булгари. Бииләр итек - читекләр”
- Магнитофон
- Ноутбук

***Мәгълүмат әсбаплары***

- Татар язучылары һәм шагыйрьләре
- Татар халык сәнгате
- Әкиятләргә иллюстрацияләр
- Татарстан Республикасы турында белешмә
- Яр Чаллы шәһәре турында белешмә
- Трафаретлар / орнаментлар
- Идел буе халыклары уеннары

***Татар әдәбияты***
- Балалар өчен шигырьләр
- Г. Тукай “Кәҗә белән сарык әкияте”
- Г. Тукай “Энҗе бөртекләре”
- Әкияттә хикмәт бар
- Һади Такташ “Тәүфиклы песи”
- Рафаил Төхфәтуллин “Ничек дәү үсәргә ?”
- Абд.Алиш “”Нечкәбил”
- Абд.Алиш “Бикбатыр белән Биккуркак”

***2. “Музыкаль» почмак***
***Уен кораллары***
- Гармун, микрофон, металлофон, гитара, бубен, торба, шалтыравыклар, маракас, пианино

***Ясалма уен кораллары***
- Маракас

3. ***“Гаилә” почмагы***
- Савыт-саба
- Җиләк-җимеш
- Алъяпкыч,яулык
- Үтүкләү тактасы
- Үтүкләр
- Кер юу машинасы
- Курчаклар
- Курчаклар өчен кровать
- Коляска
- Кибеткә йөрер өчен кәрзин
- Өстәл,урындыклар

***4. “Театр” почмагы***
- Кул курчаклары, атрибутлар, тылсымлы капчык, театр өчен битлекләр.
- Дидактик уеннар

***5. Спорт җиһазлары***
- Туплар, шалтыравыклар, сыбызгы, бубен, капчыклар, флаглар, обручлар , кольцеброслар.

***Ясалма чыныктыру җиһазлары***
- Массаж келәмчеге, пробкалардан келәмчек.

***6. “Табигать” почмагы***
***Үстерүче уеннар***
- “Йорт хайваннары”
- “Продуктлар”
- “Баласын тап”
- “Хайваннар һәм аларның балалары”
- “Рәсемнәрне бер рәткә җый”
- “Табигать күчтәнәчләре”
- “Агачлар”
- «4 сезона»: кыш, яз, җәй, көз.

***Күрсәтмә әсбаплар***

- «Рәсемнәр буенча хикәяләр төзү»: кыш, яз, җәй, көз.
- «Ел фасыллары алгоритмы»
- «Хайваннар, җиләкләр, кошлар»
- «Агачлар, куаклар, гөмбәләр»
- «Безнең як кошлары»
- «Чәчәкләр»
- «Киемнәр»
- «Кошлар»
- «Бүлмә гөлләре»
- Муляжлар: җиләкләр, җиләк-җимешләр, яшелчәләр, кыргый һәм йорт хайваннары.

***7.“Сөйләм үсеше” почмагы***

***Үстерүче уеннар***

- “Тизәйткечләр”
- “Развиваем речь”
- Дидактик уен “Төс,форма,размер”
- “Сюжетлар буенча хикәя төзе”
- “Говорящие слова ”

Шулай ук төркем кибет, чәчтараш, гаилә, шифахәнә, даруханә, транспорт, сюжетлы-рольле уеннар өчен җиһазлар һәм әсбаплар белән тулыландырылган.

### *3.4.* Материаль-техник тәэмин ителеш:

ноутбук, дисклар, уенчыклар өчен шкафлар.

# Кушымталар:

**Кушымта 1**

**Балаларның яшь үзенчәлекләре**
**Беренче кече яшьтәгеләр төркеме (1 яшьтән 2 яшькә кадәр)**

Яшәешнең икенче елында балаларның мөстәкыйльлеге үсә, предметлы уен эшчәнлеге формалаша, сюжетлы уен элементлары барлыкка килә. Өлкән кеше белән аралашу ситуацияле-эшлекле, аннары эшлекле хезмәттәшлек төсе ала. Аңга кабул итү, сөйләм, күрсәтмә-хәрәкәтле фикерләү, чынбарлыкны сиземләп кабул итү камилләшә.

Авырлык ай саен 200–250 г га арта, буй үсеше 1 см тәшкил итә. Эчке органнарның, сөяк, мускуллар һәм үзәк нерв системасының төзелеше һәм функцияләре камилләшү дәвам итә. Нерв күзәнәкләренең эшчәнлеге арта. Актив уяулык халәтенең дәвамлылыгы яшь ярымга кадәрге балаларда — 3–4 сәгать, ике яшьлек балаларда 4–5,5 сәгать тәшкил итә.

Баланың төп хәрәкәтләре үсешенә өлешчә аның гәүдә пропорцияләре (кыска аяклар, озын гәүдә, зур баш) йогынты ясый. Яшь ярымга кадәр сабый йөргәндә еш егыла, вакытында туктап кала, тоткарлыкны әйләнеп уза алмый. Гәүдәнең торышы да тотрыклы түгел. Мускуллар системасының җитәрлек дәрәҗәдә үсмәве нәтиҗәсендә балага озак вакыт бер типтагы хәрәкәтләр башкару, мәсәлән, әнисе белән «кулга тотынып кына» йөрү кыен. Яшәешнең икенче елында балаларга югары хәрәкәтләнү активлыгы хас.

Акрынлап, йөрү камилләшә. Балалар һавада йөргәндә иркен хәрәкәтләнергә өйрәнәләр: алар калкулыкларга менәләр, үләндә йөриләр, кечерәк тоткарлыклар, мәсәлән, җирдә яткан таяк аша атлап чыгалар. Аякны ышкып йөрү юкка чыга. Хәрәкәтле уеннарда һәм музыка дәресләрендә балалар янга атлау күнекмәләрен үзләштерәләр, акрын гына урында бөтереләләр.

Икенче яшькә кергәч, балалар күп һәм теләп үрмәлиләр: биек урыннарга, диваннарга, ә соңрак (бер аяклап) швед стенкасына менәләр, шулай ук бүрәнә аркылы, кыршау аша шуышып чыгалар, эскәмия астына шуышып керәләр. Яшь ярымнан соң төп хәрәкәтләрдән тыш сабыйларның охшату хәрәкәтләре дә (аю баласына, куян баласына) үсеш кичерә.

Гади хәрәкәтле уеннарда һәм биюләрдә балалар үз хәрәкәтләрен һәм гамәлләрен бер-берсенеке белән яраклаштырырга гадәтләнәләр (катнашу- чылар саны 8–10 кешедән артмаганда).

Эшчәнлекнең төрле төрләрендә сиземләү тәҗрибәсе баетыла. Предметлар белән танышу процессында бала аларның формалары атамаларын (шакмак, кечкенә кирпеч, шар, «түбә» — призма) ишетә, бер үк вакытта аларны өйрәнә, физик сыйфатларын ачыклый: предметны сыпыра-сыйпый, бармакларын аның контуры буйлап йөртә, шакый-шакылдата, ыргыта һ.б. Шул ук вакытта ул төп фигуралар (квадрат, турыпочмаклык, түгәрәк, өчпочмак) белән дә таныша. Өлкән кеше ярдәмендә бала бер үк атамалы предметлар арасындагы охшашлыкларны һәм аерымлыкларны билгеләргә өйрәнә (зур кызыл туп — кечкенә зәңгәр туп, зур ак аю баласы — кечкенә кара аю баласы һ.б.).

Өйрәнгәндә һәм уен материалын дөрес сайлаганда, балалар төрле уенчыклар — җыелма (пирамидалар, матрешкалар һ.б.) һәм сюжетлы уен- чыклар (атрибутлы курчаклар, аю балалары), төзелеш материалы белән төрле гамәлләр кылуны үзләштерәләр. Бу гамәлләрне бала өлкән кеше күрсәткәннән соң кабатлый. Акрынлап аерым гамәлләрдән «чылбырлар» оеша, сабый предметлы шөгыльләрне ахыргача җиткерергә өйрәнә: төсләре һәм зурлыклары буенча сайлап алып, тишекле түгәрәкләр белән бөтен пирамиданы җыеп бетерә, үрнәк буенча, шуннан соң хәтергә таянып, төзелеш материалыннан койма, паровоз, манара һ.б. катлаулы булмаган корылмалар төзи.

Сюжетлы уенчыклар белән эш итүдә дә зур үзгәрешләр бара. Алар бер уенчык (курчак) белән өйрәнелгән гамәлне башка уенчыкларга (аю балалары, куян балалары) күчерә башлыйлар; алар актив рәвештә гамәлне төгәлләү өчен кирәкле предметны (курчакны йокларга яткыру өчен юрган, аю баласын ашату өчен савыт) эзлиләр.

Бер-бер артлы 2–3 гамәлне башкарганда, балалар башта моның тормышта ничек булуына ориентлашмыйлар: мәсәлән, йоклаучы курчакны кинәт машинада йөртә башлыйлар. Ике яшь тулганда инде уен гамәлләрендә алар өчен гадәти тормыш эзлеклелеге чагыла: курчакны һавада йөрткәннән соң, аны ашаталар һәм йокларга яткыралар.

Балалар сюжетлы уенчыклар белән көнкүрештәге гамәлләрне мәктәпкәчә чорның бөтен дәвамында башкаралар. Ләкин шул ук вакытта 3–5 яшьлек балалар һәм өлкәнрәкләр һәр гамәлдән «күпбуынлы ритуал» ясыйлар. Ашату алдыннан курчакның кулларын юдыралар, салфетка бәйлиләр, ботканың кайнар булу-булмавын тикшерәләр, кашыктан ашаталар, чынаяктан эчертәләр.

Яшәешнең икенче елында боларның берсе дә юк. Бала бары тик савытны курчак авызы янына китерә. Башка ситуациядә дә ул шулай итә. Сюжетлы уенчыклар һәм аларга карата атрибутлар сайлау гадилеге әлеге үзенчәлекләр белән аңлатыла. Яшәешнең икенче елында аерым гамәлләрдән мәктәпкәчә балачакка хас эшчәнлек элементлары (предметлы уен, конструктив һәм сюжетлы уен) оеша. Предметлы эшчәнлектә тәңгәлләштерүче эш коралы кулланыла торган гамәлләр барлыкка килә.

Предметлы-уен эшчәнлегендәге уңышлар бу эшчәнлекнең тотрыксызлыгы белән чиратлаша. Күз уңына эләккән теләсә кайсы предмет янына бару мөмкин булганлыктан, бала кулындагы әйберне ташлый һәм шул предмет янына омтыла. Өлкән кеше ярдәмендә ул, нәтиҗәгә ирешү өчен, тора-бара башлаганны ахыргача җиткерергә өйрәнә.

Яшәешнең икенче елы — сөйләмнең интенсив формалашу чоры. Предмет, гамәл һәм аларны белдерүче сүзләр арасындагы бәйләнешләр яшәешнең беренче елы ахырындагыга караганда 6–10 тапкыр тизрәк формалаша.

Балалар предметларның, гамәлләрнең исемнәрен, кайбер сыйфатларның һәм халәтләрнең аталышларын үзләштерәләр. Шуның нәтиҗәсендә сабыйларның эшчәнлеген һәм үз-үзләрен тотышларын оештырырга, аңга кабул итүне, шул исәптән сиземләү аша кабул итү нигезен хасил итүче сыйфатларны формалаштырырга һәм камилләштерергә мөмкин.

Өлкәннәр белән бергә төрле эшчәнлек процессында балалар бер үк төрле гамәлнең төрле предметларга карата ярашырга мөмкин булуын үзләштерәләр («башлыкны ки, пирамидага боҗралар (түгәрәкләр) кидер» һ.б.). Яшәешнең икенче елында формалашучы гомумиләштерү сәләте сөйләмнең һәм фикерләүнең мөһим казанышы булып тора. Бала аңында сүз, бер предмет белән генә ассоциацияләшеп калмыйча, төсләрендә, зурлыкларында һәм хәтта тышкы кыяфәтләрендә аермалар булуга карамастан, шул төркемгә кергән барлык предметларны белдерә башлый (зур һәм кечкенә, ялангач һәм киенгән курчак, малай курчак һәм кыз курчак). Ел башында берәр төрле предметны күрсәтергә кушканда сабый очраклы, мөһим булмаган билгеләргә ориентлашкан булса, хәзер инде гомумиләштерү сәләте балаларга рәсемдә күрсәтелгән предметларны танырга мөмкинлек бирә. Элек, мәсәлән, «кх» сүзе белән сабый песине дә, мехлы яканы да белдерергә мөмкин иде.

Сабый предметлар арасында төрле бәйләнешләр булуына, өлкәннәрнең һәм балаларның төрле хәлләрдә һәм шартларда эш итүләренә күнегә, шуңа күрә сюжетлы сәхнәләштерүләр (уенчыклар, курчак һәм өстәл театры персонажларын күрсәтү) аның өчен аңлаешлы була.

Шундый күрсәтүләр, кызыксынып күзәтү вакытында алган тәэсирләр хәтердә саклана. Шуңа күрә яшь ярымнан өлкәнрәк балалар үз тәҗрибәләренә бәйле күптән түгел булган вакыйгалар яки әйберләр турында өлкән кеше белән диалог-истәлек алып барырга сәләтле («Кем йөргән?» — «Нәрсә күргәннәр?» — «Көчекне». — «Кемгә ярма бөртекләре ашатканнар?» — «Кош- чыкка».

Ел дәвамында актив сүзлек тигезсез рәвештә арта. Яшь ярымлык вакытта ул 20–30 сүз чамасы тәшкил итә. 1 ел 8–10 айдан соң сикереш күзәтелә, актив кулланыштагы сүзлек үсә. Ул сүзлектә фигыльләр һәм исемнәр күп була, гади сыйфатлар һәм рәвешләр (монда, тегендә, шунда һ.б.), шулай ук бәйлекләр очрый.

Гадиләштерелгән сүзләр (ту-ту, ау-ау һ.б.) гадәти, фонетик яктан камил булмаган сүзләр белән алыштырыла. Яшь ярымнан соң бала сүзнең контурын (төрле сандагы иҗекләр) ешрак куллана, аны ишетелүче сүзнең яңгырашына азмы-күпме якын алмаш авазлар белән тутыра.

Бу яшьтә өлкән кеше артыннан кабатлап, әйтелешне яхшырту омты- лышлары уңыш китерми. Бу фәкать яшәешнең өченче елында гына мөмкин була. Яшь ярымнан соң күпчелек очракларда бала ирен-ирен авазларын
(п, б, м), алгы аңкау-тел (т, д, н), арткы аңкау-тел (г, х) авазларын дөрес әйтә. Бала кулланган сүзләрдә сызгырулы, чыжылдаучы һәм сонор авазлар, шулай ук кушылма фонемалар бик сирәк очрый.

Башта бала әйткән сүз тулы бер җөмләне аңлата. Мәсәлән, «ап итте» сүзләре бер очракта — сабыйның уенчыкны төшереп җибәрүен, башка очракта аның егылуын һәм бәрелүен белдерә.

Яшь ярымга җиткәндә, балалар сөйләмендә ике сүзле җөмләләр барлыкка килә, икенче ел ахырында өч, дүрт сүзле җөмләләр куллану гадәти күренешкә әверелә.

Яшь ярымнан өлкәнрәк бала актив рәвештә өлкәннәргә сораулар бирә. Сорауларны ул башлыча интонация рәвешендә белдерә («Гү әм?» — «Гүзәл ашадымы?»). Сорау сүзләрен балалар сирәгрәк куллана, алар «Яулык кайда?», «Әби кая китте?», «Бу нәрсә?» дип сорарга мөмкин.

Балалар өлкәннәрнең кушканын күренерлек, күрсәтмәле шартларда үтәргә өйрәнәләр.

Яшәешнең икенче елында бала үзе көн саен аралаша торган өлкәннәрнең һәм балаларның исемнәрен, шулай ук кайбер туганлык мөнәсәбәтләрен (әни, әти, әби) үзләштерә. Ул «сөенә», «ачулана», «курыкты», «кызгана» сүзләре белән белдерелүче элементар кеше хис-тойгыларын һәм кичерешләрен аңлый. Сөйләмдә бәяләмә фикерләүләр — «начар», «яхшы», «матур» сүзләре барлыкка килә.

Балаларның мөстәкыйльлеге предметлы-уен эшчәнлегендә һәм үз- үзеңә хезмәт күрсәтүдә камилләшә. Акрынлап сабый теләсә нинди ризыкны мөстәкыйль ашау, юыну һәм кулларын юу сәләтен, пөхтәлек, җыйнаклык күнекмәләрен үзләштерә.

Якын-тирәлектә ориентлашу киңәя. Төркем бүлмәсе өлешләренең ничек аталышын (йорт җиһазлары, кием-салым, савыт-саба) белү балага зурларның катлаулы булмаган (бер, ә ел ахырына 2–3 гамәлдән торган) йомышларын үтәргә ярдәм итә. Акрынлап ул үз-үзеңне тотуның «мөмкин», «ярамый», «кирәк» сүзләре белән белдерелүче элементар кагыйдәләрен үтәргә гадәтләнә. Өлкән кеше белән аралашу эшлекле, объектлы-юнәлтелгән асылга ия.

Яшәешнең икенче елында өлкән кеше белән эшлекле хезмәттәшлек, төрле сәбәпләр аркасында аның белән аралашу ихтыяҗы ныгый һәм тирәнәя. Ике яшь тулганда балалар акрынлап ишарәләр, мимика, тәэсирле сүзтезмәләр теленнән үтенечләрне, теләкләрне, тәкъдимнәрне сүзләр һәм кыска гыйбарәләр белән белдерүгә күчәләр. Шулай итеп, сөйләм өлкән кеше белән аралашуда төп чарага әверелә; бу яшьтә бала якыннары, аңа яхшы таныш кешеләр белән генә теләп сөйләшә.

Яшәешнең икенче елында балалар арасында үзара эмоциональ аралашу тибы саклана һәм үсеш кичерә. Алар мөстәкыйль рәвештә бер-берсе белән (икешәрләп-өчәрләп) элегрәк өлкән кеше ярдәмендә өйрәнелгән уеннарны («Качышлы», «Куышлы») уйныйлар.

Ләкин балаларның үзара аралашу тәҗрибәсе зур түгел, һәм аның нигезе әле формалашмаган. Фаразланган партнер ягыннан аңлашмау очрагы күзәтелә. Бала елап җибәрергә һәм хәтта аны кызганучыга сугарга да мөмкин. Ул үз уенына тыкшынуга каршы актив рәвештә протест белдерә.

Башка бала кулындагы уенчык, янәшә торганына караганда, сабый өчен күпкә кызыклырак. Күршесеннән уенчыкны тартып алып, алга таба нишләргә белмичә, сабый ул уенчыкны ташлый. Балаларда аралашу теләге юкка чыкмасын өчен, тәрбияче андый фактларга юл куймаска тиеш.

Кагыйдә буларак, көн дәвамында балаларның үзара аралашуы предметлы-уен эшчәнлегендә һәм режим процессларында туа. Предметлы-уен гамәлләре һәм үз-үзенә хезмәт күрсәтү әлегә формалашып кына килгәнгә күрә, аларны башкаруга карата кызыксыну хисен төрле юллар белән сакларга кирәк.

Балаларны «ара дисциплинасы»н сакларга өйрәтәләр, алар башта бер-берсенә комачауламыйча янәшә уйнау һәм эш итү, аннары 2–3 кеше бергә уйнау, төркемдә үз-үзләрен тиешенчә тоту (күршенең тәлинкәсенә үрелмәү, тагын бер бала утыра алсын өчен

диванда күчеп утыру, йокы бүлмәсендә шауламау һ.б.) сәләтен үзләштерәләр. Бу очракта алар гади сүзләр («мә» («ал»), «бир», «җибәр», «кирәк түгел» һ.б.) кулланалар.

Һәр сабыйның эшчәнлеген «саклау» фонында бергәләп эш итүне формалаштырырга кирәк. Башта өлкән кешенең әйтеп җибәрүе буенча, ә инде ике яшь тулганда, балалар мөстәкыйль рәвештә бер-берсенә ярдәм итәргә (күршесенә уенны дәвам итү өчен кирәкле предметны (шакмаклар, пирамида өчен түгәрәкләр, курчакка ябарга юрган) алып килү) сәләтле. Әнисенә яки тәрбиячегә охшатып, бер сабый икенчесен «ашатырга, чәчен тарарга» тырыша.

Музыка дәресләрендә сабыйларның парлашып катлаулы булмаган бию хәрәкәтләре башкарулары мөмкин.

Яшәешнең икенче елындагы төп казанышларның берсе итеп төп хәрәкәтләрне, бигрәк тә йөрүне камилләштерүне санарга мөмкин.

Баланың хәрәкәтчәнлеге кайчакта хәтта аңа тыныч дәресләрдә тупла- ныргa комачаулык итә.

Баланың үз-үзен тотышында предметлы-уен халәтенең тиз һәм төрле планлы үсеше күзәтелә, нәтиҗәдә кече яшьтәгеләрнең икенче төркемендә булуларының ахырына балаларда барлык эшчәнлек төрләренең мәктәпкәчә балачак чорына хас компонентлары формалаша.

Сөйләмнең барлык яклары һәм функцияләре тиз үсеш кичерә. Сөйләү сәләтенең элеккечә үк тирәлектәгеләрнең сөйләмен аңлау үсеше темпыннан калышуына карамастан, икенче ел ахырына инде актив сүзлек 200–300 сүздән тора. Сөйләм ярдәмендә баланы оештырырга мөмкин, ә баланың үзенең сөйләме өлкәннәр белән төп аралашу чарасына әверелә.

Бер яктан, тормышның барлык өлкәләрендә баланың мөстәкыйльлеге үсә, икенче яктан — ул төркемдә үз-үзен тоту кагыйдәләрен үзләштерә (башкаларга комачауламыйча янәшәдә уйнау, аңлашылса һәм кыен булма- са — булышу). Болар барысы да киләчәктә уртак уен эшчәнлеген үстерү өчен нигез булып тора.

**Кушымта 2**

## Белем бирү эшчәнлегенең тематикасы.

| Тема | Вакыт |
|---|---|
| Мин-дөньяның бер кешесе! | 01.09-09.09 |
| Жиләк-жимешле бакча | 12.09-16.09 |
| Көзге уңыш | 19.09-23.09 |
| Төрле төстәге көз | 26.09-30.09 |
| Икмәк ил байлыгы | 03.10-07.10 |
| Табигатьтәге үзгәрешләр | 10.10-14.10 |
| Без-тату балалар | 17.10-21.10 |
| Безнең төркем | 24.10-31.10 |
| КамАЗ | 07.11–11.11 |
| Безнең апа | 14.11-18.11 |
| Хайваннар дөньясында | 21.11-25.11 |
| Табигать дөньясында | 28.11-30.11 |
| Кыш килде | 01.12-09.12 |
| Яңа ел бәйрәменә әзерләнәбез | 12.12-16.12 |
| Яңа ел бәйрәме | 19.12-23.12 |
| Туган ягым | 26.12-30.12 |
| Әйберләр илендә | 09.01-13.01 |
| Ягымлы булыйк! | 16.01-20.01 |
| Яраткан шәһәрем! | 23.01-31.01 |
| Киемнәр | 01.02-10.02 |
| Ашамлыклар | 13.02-17.02 |
| Яраткан әтием | 20.02-28.02 |
| Ямьле яз | 01.03-03.03 |
| Яраткан Әнием | 06.03-10.03 |
| Сәламәт булыйк! | 13.03-17.03 |
| Агачлар | 20.03-24.03 |
| Кошлар | 27.03-31.03 |
| Урманда – яз | 03.04-07.04 |
| Гөлләр карыйбыз! | 10.04-14.04 |
| Минем гаиләм | 17.04-21.04 |
| Г.Тукай-безнең күңелләрдә | 24.04-28.04 |
| Дус уйныйбыз! | 02.05-05.05 |
| Уенчыклар | 08.05-12.05 |
| Әкият илендә | 15.05-19.05 |
| Исәнме, җәй! | 22.05-31.05 |

**Кушымта 3**

**I кечкенә нәниләр төркемендә белем бирү өлкәләре түбәндәгечә:**

| **Оештырылган белем бирү өлкәләре** | **Саны** |
|---|---|
| Танып белү (Әйләнә тирәдә ориентлашуны киңәйтү) | 1 |
| Дидактик материаллар белән уен | 2 |
| Коммуникация(Сөйләм үстерү) | 1 |
| Төзү материаллары белән уен | 1 |
| Хәрәкәтне үстерү | 2 |
| Матур әдәбият белән таныштыру | 1 |
| Музыка | 2 |
| **Барлыгы:** | **10** |

**8 нче төркемнең белем бирү эшчәнлеге челтәре**

ФГОС таләпләренә Физкультура туры килгән белем өлкәләреннән чыгып, балаларның яшь үзенчәлекләре һәм СанПин таләпләренә туры китереп, **атналык оештырылган белембирү эшчәнлеге челтәре** төзелде.

| | | |
|---|---|---|
| Дүшәмбе | **1**. Дидактик материаллар белән уен<br><br>2. Хәрәкәтне үстерү | I. 9.00 - 9.10<br>II. 9.20 - 9.30<br>I. 15.30 - 15.40<br>II.15.50 - 16.00 |
| Сишәмбе | 1.Төзү материаллары белән уен:<br><br>2. Коммуникация (Сөйләм үстерү): | I. 9.00 - 9.10<br>II. 9.20 - 9.30<br>I. 15.30 - 15.40<br>II.15.50 - 16.00 |
| Чәршәмбе | 1. Хәрәкәтне үстерү:<br>2. Дидактик материаллар белән уен: | I. 09.00 - 09.10<br>II.09.20 - 09.30<br>I. 15.30-15.40<br>II.15.50 - 16.00 |
| Пәнҗешәмбе | 1. Музыка:<br>2. Танып белү (Әйләнә тирәдә ориентлашуны киңәйтү) | 08.50 – 09.00<br>I. 15.30 - 15.40<br>II.15.50 - 16.00 |
| Җомга | 1. Музыка:<br>2. Матур әдәбият уку: | 08.50 – 09.00<br>I. 15.20 - 15.30<br>II.15.40 - 15.50 |

**Кушымта 4**

## 3.6. Сәламәтләндерү чаралары
## Балаларны балалар бакчасына кабул итү, тәрбия-белем бирү эшчәнлеген оештыру таләпләре. (СанПиН 2.4.3648-20 (28 сентябрьдән 2020 ел)

**Балаларны балалар бакчасына кабул итү, тәрбия-белем бирү эшчәнлеген оештыру таләпләре. (СанПиН 2.4.3648-20 ).**

Балаларны иртән кабул итү тәрбиячеләр яки медицина хезмәткәрләре тарафыннан ата-аналардан баланың сәламәтлеген сораудан башлана. Күрсәткечләр буенча термометрия үткәрелә.Авыру, авыруга шик тудырган балалар бакчага кабул ителмиләр, көн дәвамында авыручыларны ата-аналары килгәнче яки ата-аналарга хәбәр итеп дәвалау оешмасына җибәргәнче башка сәламәт балалардан аералар. Авырудан соң һәм бала 5 көннән озаграк(бәйрәм, ял көннәреннән башка) килми торганнан соң балалар бакчасына авыруның диагнозы, авыру дәвамлыгы, йогышлы авырулар белән бәйләнеше булмау турындагы справка булганда гына кабул ителә.

Көн тәртибе балаларның яшь үзенчәлекләреннән чыгып төзелә һәм гармонияле үсешенә булыша. 1-2 яшьлек балаларның иң күп өзлексез уяулык вакытының дәвамлыгы 4,5-5 сәгать. Тәкъдим ителгән көндәлек прогулкаларның дәвамлыгы-3-4 сәгать. Саф һавада булуның озынлыгы табигать шартларыннан да бәйле. Һава температурасы минус 15 °С түбән, җилнең тизлеге 7 м/с тан югары булганда саф һавада булу вакыты кыскартырга киңәш ителә.

Саф һавада йөрүне көнгә 2 тапкыр: көннең беренче яртысында һәм көннең икенче яртысында – көндезге йокыдан соң яки балалар өйгә кайтып китәр алдыннан тәкъдим ителә.

Балалар 5 сәгатьтән күбрәк булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар оешмасында 3-4 сәгать аерма белән ашау һәм көндезге йокы оештырыла. Балаларның көнлек йокысы 12-12,5 сәгать булырга тиеш, шуның 2,5-3 сәгате көндезге йокыга бирелә. Йокы алдыннан хәрәкәтле уеннар, чыныктыру чаралары үткәрү тыела. Балалар йоклаганда тәрбияченең (яки аның ярдәмчесе) булу мәҗбүри.

Көн тәртибендә 1-2 яшьлек балаларга мөстәкыйль эшчәнлек (уеннар, шәхси гигиена, уку эшчәнлегенә әзерләнү) өчен кимендә 4-5 сәгать вакыт бирелергә тиеш.

1-2 яшьлек балаларда оешкан белем бирү эшчәнлегенең дәвамлыгы 10 минуттан артмаска тиеш, аларны уен мәйданчыгында саф һавада үткәрергә дә мөмкин.

Балалар бакчасында режим вакытларын үткәргәндә түбәндәге таләпләр саклана:

- балаларның организымнарын тулысынча һәм вакытында ял иттерү;
- тулысынча гигиена таләпләрен үтәү, тәннәрнең, киемнең, урын-җирнең чисталыгын булдыру;
- көчләреннән килгәнчә балаларны режим вакытларына тарту, мөстәкыйльлек һәм активлык өчен мактау;
-культура гигиена күнекмәләрен формалаштыру;
- режим процессларын үтәү барышында эмоциональ аралашуы;
- балаларның шәхси сәләтен, таләпчәнлеген исәпкә алу;
- тәрбияченең балалар белән тыныч һәм ягымлы сөйләме, балага сак мөнәсәбәт;
- балаларның аппетиты һәм йокысы аларның нерв системасыннан бәйле булганлыктан, озак көтүне булдырмау.

**ЙОКЫДАН УЯНУ ГИМНАСТИКАСЫ**

**Комплекслы-тематик план**

| **Ай** | **Гимнастика** |
|---|---|
| сентябрь | «Уяну»<br>Йокы качты тәрәзәдән, йөгерде юллардан,<br>Ә без синен белән уяндык, уяндык та елмайдык (киерелү)<br>Башта күзләрнен берсен ачтык, аннары икенчесен,<br>Кулларны күтәреп төшердек, велосипед әйләндердек.<br>Уңга-сулга борылдык, аннары сикереп тордык. |
| октябрь | «Хәерле иртә»<br>Хәерле иртә, күзләр. Сез уяндыгызмы?(күзләргә массаж. Бармаклар белән бинокль ясап, як-якка карыйлар)<br>Хәерле иртә, колаклар. Сез уяндыгызмы?(колакларга массаж. Учны колакларга куялар (“Чебурашка”), як-якны тыңлыйлар)<br>Хәерле иртә, куллар. Сез уяндыгызмы?(кулларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Пропеллер” күнегүе)<br>Хәерле иртә, аяклар. Сез уяндыгызмы?( аякларның башта берсенә, аннан икенчесенә массаж. “Велосипед” күнегүе)<br>Хәерле иртә, кояш. Мин уяндым!( кулларны сузып киерелү) |
| ноябрь | Әйдәгез, бергәләп, басабыз,<br>Кулларны ян – якка сузабыз.<br>Аннары бөгеләбез,бергәләп тураябыз.<br>Кулларны күтәрәбез,<br>Кояшка сәләм юллыйбыз.<br>Кулларны качырабыз,<br>Аннары аларны бергәләп эзлибез.<br>Уңга карыйк,<br>Сулга борылыйк.<br>Утырабыз, торабыз.<br>Үкчәгә дә басыбыз,<br>Аяк очларына басып,<br>Кояшка үреләбез. |
| декабрь | «Без шулай итәбез»<br>Без йоклап тордык, бераз уйнарга булдык.<br>Башны иябез алга, уңга, сулга борабыз,<br>Аннан карап торабыз.<br>Иң өсләрен сикертәбез, кулларны биетәбез.<br>Бер алга, бер артка сузып,<br>Күңелле ял итәбез.<br>Аннары без чүгәлибез, тезләрне кочаклыйбыз.<br>Башны алга яшереп, без ападан качабыз. |
| январь | «Пескәй »<br>1. “Пескәй уяна”. Ятып, бергә уң аякны һәм сул кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан сул аякны һәм уң кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан 2 кулны һәм 2 аякны бергә күтәрәләр, төшерәләр. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>2. «Пескәй сөенә». Үрмәләү позасына керергә. Башны күтәрергә, умыртка сөяген бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>3.«Пескәй ачулана ». Үрмәләү позасына керергә. Иякне күкрәккә тидерергә, арканы бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга. |

| | |
|---|---|
| | 4. “Пескәй сузыла”  Сузылу күнегүе.<br>5. “Пескәй сикерә” Сикерү. |
| февраль | “Чәчәк”<br>Чәчәк йоклый,<br>Чәчәк уяна. (киерелү күнегүләре)<br>Иртәнге кояшка<br>Ул бик куана. (урында сикерү)<br>Кояшка сузыла (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Кояшка үрелә (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Күбәләк дустына (кулларны канатлар каккан кебек җилпиләр)<br>Сәлам өләшә (сәлам бирәләр) |
| март | Без уяндык, (киерелү күнегүләре)<br>Күзләрне ачтык, (күзләрен ачалар)<br>Аякларны суздык (аякларын сузып, селкетәләр)<br>Аларны да уяттык!<br>Ян –якка борылып (басып, ян –якка борылалар)<br>Кояшка без карадык. (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Якты көнгә сокланып,<br>Матур итеп елмайдык. (ян – якка борылып, елмаялар)<br>Сикереп тә алдык (сикерү күнегүләре)<br>Йөгердек тә (урында йөгерү)<br>Хәзер инде без<br>Уйнарга бергә әзер! (үз-үзеңне кочу) |
| апрель | Аякларың тыпырдат (аякларны тыпырдаталар)<br>Кулларыңны чәбәклә.(кулларны чәбәклиләр)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кыен эш түгел бер дә. (ян-якка борылып кулларны чәбәклиләр)<br>Башың аска иеп ал, (башларын бер иеп, бер күтәрәләр)<br>Кулларыңны болгап ал. (йөзү күнегүләре)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кулларыңны болгап ал.(ян- якка борылып, йөзү күнегүләре эшлиләр)<br>Бу дустың белән күреш, (уңга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Бу дустың белән күреш.(сулга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Йә иптәш, йә, әйлән, (урында сикереп, әйләнәләр)<br>Бик кыен түгел бу эш. |
| май | Нәниләр бара тигез юл буйлап. (урында атлыйлар)<br>Тигез юл буйлап, ашыкмый атлап. (урында атлыйлар)<br>Зур-зур ташларны<br>Сикереп үтәләр. (урында сикерәләр)<br>Уңга да баралар, сулга да баралар, (уңга – сулга борылу күнегүләре)<br>Су аша йөзеп, (йөзү күнегүләре)<br>ярга чыгалар. (сулыш алу күнегәләре) |